• КОРБАН ЧАЛУ •
КОРБАННЫҢ ТӨП КАГЫЙДӘЛӘРЕ
4 бит

• САБЫЙГА •
ДИН – БӘХЕТКӘ ЮЛ
9 бит

• НӘСЫЙХӘТ •
АТА-АНАГА ИТАГАТЬ КЫЛУ
12 бит

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
ОЛУГ ҮКЕНЕЧ
14 бит

№ 7 (300) | Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы | зөлхиҗҗә 1441

Июль, 2020

дين ومعيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Корбан бәйрәме турында нәрсә белергә кирәк?




Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһиүмәссәлам пәйгамбәрләрдән калган йола. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманыннан бирле ел саен үткәрелеп килә торган вәҗиб гамәл. Аллаһыга якынаю ысулы. Фәкыйрьләргә ярдәм кулы сузу вакыты... Сүз, әлбәттә, Корбан гаете турында бара. Безгә бу олуг бәйрәм турында тагын нәрсәләр белергә кирәк соң?..


*Дәвамы 4 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Кәлам Шәрифнең махсус тиражы

**Нәзарәткә төбәкләрдәге милләттәшләр өчен Коръәннең татарчага тәрҗемәләренең махсус тиражы кайтты.**




16 нчы июльдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясенә “Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә” басмасының беренче махсус тиражы кайтты. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин йөкләмәсе буенча, Коръән мәгънәләренең татар теленә тәрҗемәләре мөфтиятнең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан Туган тел елы кысаларында татарлар күпләп яшәгән Рәсәй төбәкләре өчен максатлы тираж буларак дөнья күрде. 600 данә китап иң беренче булып Башкортстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте мәчетләренә җибәрелде. Бу хакта Камил хәзрәт Сәмигуллин Башкортстан мөфтие Айнур хәзрәт Биргалин белән очрашу вакытында хәбәр итте. Шул рәвешле, БР МДН карамагында эшләгән барлык мәчетләр дә татар телле заманча дини-илаһият хезмәте белән тәэмин ителәчәк. Билгеле булганча, китап Татарстанда гына түгел, чит төбәкләрдә дә зур популярлык казанып өлгерде.

Исегезгә төшерәбез, “Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә” басмасы ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 2019 елда Тәфсир елы кысаларында нәшер ителде. Татар телендәге басма белән беррәттән, шулай ук рус телендә «Калям Шариф. Перевод смыслов» китабы да дөнья күрде. Китаплар Мәскәүдә һәм Махачкалада зур уңыш белән тәкъдим ителде. Рус телендәге басма “Хозур” нәшрияты тарафыннан өч тапкыр нәшер ителде (гомуми тиражы 7 мең данә). Татар телендә хезмәт 3 тапкыр 4 меңлек гомуми тираж белән бастырылды. Моннан тыш, “Хозур” нәшрияты тарафыннан Коръән мәгънәләренең татар теленә тәрҗемәләре аудиоверсиясе әзерләнде, соңыннан ул Коръән-каләмгә кертелде.

■ dumrt.ru

# РИИ һәм КИУ-да кабул итү кампаниясе

**Рәсәй ислам институтында һәм Казан ислам университетында 2020-2021 уку елларында белем алу өчен документларны кабул итү дәвам итә.**

Рәсәй ислам институты бакалавриат программасы буенча “Теология”, “Лингвистика”, “Журналистика” бүлекләренә, магистратура программасы буенча “Теология” һәм “Лингвистика” программаларына документлар кабул итә. Көндезге һәм читтән торып уку каралган. “Теология” бүлегендә уку читтән торып дистант уку технологияләрен кулланып оештырыла.

Казан ислам университетында исә “Дини оешмалар өчен дин әһелләре һәм хезмәткәрләр әзерләү” бүлегендә “Ислам фәннәре” һәм “Коръән фәннәре” (Коръән хафизлары әзерләү үзәге) дигән юнәлешләре бар. Көндезге, кичләрен яки читтән торып уку мөмкин.

Шулай ук урта дини һөнәри белем (мәдрәсә) программасында читтән торып дистант уку технологияләрен кулланып белем алып була.

Гаризаны биргәндә паспорт копиясе, 3х4 күләмдәге 8 фотография, урта белем таныклыгы, ЕГЭ нәтиҗәләрен китерергә кирәк. Документларны кабул итү 16 августка кадәр дәвам итәчәк. Урта һөнәри һәм югары уку йортларын тәмамлаганнар өчен кабул итү сынаулары 17-22 августта булачак.

Рәсәй ислам институты 2019 елда белем бирү эшчәнлегенең дәүләт аккредитациясен уңышлы узды һәм укып чыкканнарга дәүләт дипломнарын тапшыра. РИИ шәкертләренә хәрби хезмәткә баруны кичектереп торырга рөхсәт ителә.

Укырга керер өчен документларны читтән торып та җибәреп була. Бу мөмкинлек турында һәм уку йортына керү турындагы тулырак мәгълүматны РИИ (http://kazanriu.ru/) һәм КИУның (http://kazankiu.ru/) рәсми сайтларында “Абитуриентларга” бүлегендә алып була. Кабул итү комиссиясенә сораулар белән 8 (843) 251-01-55 телефоны аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Кабул итү комиссиясенең адресы: Казан шәһ., Газовая ур., 19 йорт, 109 каб.

■ dumrt.ru

# Мөселманнарга ярдәмгә Нәзарәттә мәетләр җирләү хезмәте эшли башлады




Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә мәетләр җирләү хезмәте эшли башлады. Әлеге хезмәт мөэмин-мөселманнарга булышу максатыннан булдырылды, чөнки, гадәттә, якыннарны җирләү мәсьәләсе килеп баскач, кайгыдан югалып калган кешеләр тиз арада эшне оештыруга мохтаҗлык кичерә. Моннан тыш, дөрес итеп җеназа үткәрү бөтен мөселман өчен мәҗбүри дини йөкләмә (фарыз) булып тора.

Татарстан мөфтиятенең мәетләр җирләү хезмәте мөселманнарга катлаулы вакытта ярдәм итә: белгечләр халыкка тәүлек буена консультацияләр бирә, мәетне юу һәм озату мәсьәләләре буенча Казан имамнарын оештырып җибәрә, хәнәфи мәзһәбе буенча җеназа үткәрергә ярдәм итә.

Шунысы игътибарга лаек: ритуаль эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен, мөфтият карамагындагы хезмәттә ләхет һәм баш такталары (обелиск), кәфенлекләр, шулай ук кәфенлек җыелмасы җитештерү өчен цех булдырылды. Җыелма эченә нәзарәтнең “Хозур” нәшриятында басылып чыккан белешмә әдәбият та кертелде, анда мәет озату йолалары, мәетне юу, зиярат кылу тәртипләре һ.б. бәян кылына.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең мәетләр җирләү хезмәте карамагына мәетне бер урыннан икенче урынга күчерү өчен катафалкада йөртүне, кабер казуны оештыру, шулай ук ЗАГС органнарында үлү турында таныклык алуда булышлай ярдәм итү керә.

Шулай итеп, ТР мөселманнары Диния нәзарәте белгечләре мәрхүмнең туганнарына мәет озатуны оештыруның теләсә кайсы этабында ярдәм итәчәк һәм Ислам кануннары буенча күмү эшләрен һәм йолаларын гамәлгә ашырачак.

Әлеге хезмәт тәүлек буе 8(843) 203-57-07 телефоны буенча эшли.

■ dumrt.ru

# Татарстанда корбан чалу урыннары билгеләнде

**2020 елның 31 нче июлендә бөтендөнья мөселманнары төп ислам бәйрәмнәренең берсе – Корбан бәйрәмен (Гыйд әл-әдха) каршы алачак. Ел саен ул зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә билгеләп үтелә. Шулай итеп, 2020 елда Корбан бәйрәме 31 нче июльгә туры килә.**

**Казан һәм Татарстан мәчетләрендә 31 нче июль көнне бәйрәм намазын уку өчен мәчетләргә иртәнге 3:30 сәгатькә җыелырга тәкъдим ителә. Бу вакытта Коръәннән аятьләр укырга керешәчәкләр. Сәгать 3:45тә Корбан гаете вәгазьләре башланачак. Ә гает намазы сәгать 4:15кә билгеләнгән.**

**Корбанны иртәнге 4:30дан чала башларга мөмкин.**

***

Дөньякүләм пандемия – коронавирус инфекциясе таралуны булдырмый калу максатыннан, гает намазларын мөмкин булганча ачык һавада оештыру мөмкинлеген карау сорала. Корбан гаете чараларын оештырганда һәм корбанлык итләрен өләшкәндә COVID-19 таралуны булдырмау өчен, Роспотребнадзор тарафыннан тәкъдим ителгән барлык чараларны да үтәү таләп ителә: мәчетләргә бары битлек (яисә респиратор), перчатка, шәхси намазлык белән генә керү мөмкин, намаз 1,5 метр аралыкны саклап укылачак.

Корбан чалу бәйрәм намазыннан соң, башланып китәчәк һәм махсус корбан чалу урыннарында өч көн дәвам итәчәк.

ТР Министрлар кабинетының Ветеринария буенча баш идарәсе мәгълүматлары буенча, республикада аларны 55 урында оештырырга мөмкин. Әмма, пандемия аркасында, Диния Нәзарәтенең мөхтәсибәтләре тарафыннан аларның саны киметелде. Шул рәвешле, корбан чалырга теләүче дин кардәшләр моны мөфтиятнең мөхтәсибәтләре карамагында эшләгән 33 мәйданчыкта башкара ала (аста китерелгән исемлеккә өстәмәләр кертелергә мөмкин). Корбанны шулай ук шәхси цехларда һәм шәхси хуҗалыкларда чалырга мөмкин.

Казанда корбан чалу 15 мәйданчыкта башкарылачак:

| № п/п | Оешма / мәчет | Адрес, телефон |
|---|---|---|
| 1. | «Казан Нуры» | Фатыйх Әмирхан ур., 3<br>523-16-55 |
| 2. | «Салихҗан» | Бестужев ур., 66а<br>513-66-50 |
| 3. | «Әл-Мәрҗани» | Каюм Насыйри ур., 17<br>293-36-86 |
| 4. | «Гадел» | Оренбург проезды, 193<br>269-50-37 |
| 5. | «Ризван» | Хөсәин Мәүлетов ур., 48а<br>224-38-47 |
| 6. | «Апанай» | Каюм Насыйри ур., 27<br>293-42-92 |
| 7. | «Тынычлык» | Мелитопольская ур., 15 (Тынычлык)<br>266-34-04 |
| 8. | Бертуган Петряевлар урамындагы комплекс | Бертуган Петряевлар урамы |
| 9. | «Рамазан» | Окольная урамы, 25б 260-03-13 |
| 10. | «Мәүлид» | Селянская урамы, 23 (Залесный) |
| 11. | «Коддус» | Яснополянский тыкрыгы, 16 (Карьер)<br>+7 937 776-07-74 |
| 12. | «Иман Нуры» | Дорожная урамы, 32а (Нагорный)<br>+7 919 691-19-81 |
| 13. | «Фатиха» (Кадыш мәчете) | Рихард Зорге урамы, 2а, (Кадыш)<br>+7 927 245-66-72 |
| 14. | «Рәҗәп» | Энгельс урамы, 20 |
| 15. | «Сөләйман» | Ютазы урамы, 8а к1<br>512-03-77 |



**Фото Бизнес-онлайн сайтыннан**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды шулай ук корбанлыкларга гаризалар кабул итә. Теләгән һәркем фондтан сарыклар сатып алып, корбан чалып, аның итен аз керемле гаиләләргә, инвалидларга, авыр хәлдә калган кешеләргә, ятимнәргә тапшырырга мөмкин. "Зәкят" фонды барлык оештыру мәсьәләләрен хәл итүне үз өстенә ала: күпләп сатып алу бәясеннән сарыклар тәкъдим итү, мохтаҗларга өләшү һ.б. Моннан тыш, фондта корбан чалу буенча квалификацияле белгечләр һәм корбанлыкларны алып килүчеләр белән киңәшләшергә мөмкин. Фондның хезмәтләре – бушлай. Сарыкларның бәясе – 8000 сум. Белешмәләр өчен телефон: 225-33-22.

**dumrt.ru**

# Корбанның төп кагыйдәләре

– корбан итен сатарга яки аны түләү сыйфатында кулланырга ярамый;

– җәмгыять өчен корбанның файдасы күбрәк булсын өчен тырышырга;

– әгәр хайванның тиресен һәм эчен куллану мөмкинлеге булса, аны ташлау хупланмый (кулланылмаган очракта күмеп куярга мөмкин);

– әгәр сөякләре файдаланылган булса, аларны этләргә бирүдән тыю юк;

– корбанлык хайванының канын, гадәти вакытта мал суйгандагы кебек, шулай ук туфрак белән күмәргә кирәк.

Әгәр хайванның карынынnan яралгы чыкса, аның үсеш стадиясе исәпкә алына. Ул тулысынча формалашкан һәм тере булса, аны чалырга кирәк, әгәр формалашмаган яки үлгән булса, аны ашау тыела һәм аны чалу берниндиг дә файда китерми.

### Хайванның тиресен:

– садака итеп бирергә;

– хуҗалыкта файдалану өчен нинди дә булса җайланма эшләргә;

– яки хуҗалыкта озак вакыт файдаланыла торган нәрсәгә дә булса алыштырырга мөмкин.

### Тәкбир әт-тәшрикъ көннәре

Гарәфә көнендә, 30 нчы июльдә, иртәнге намаздан башлап, зөлхиҗҗә аеның 13 нче көнендәге икенде намазын да (3 нче август) кертеп, егерме өч фарыз намазның һәркайсыннан соң сәлам биргәч, Аллаһы Тәгаләне олылап, Аны данлап, өч мәртәбә: «Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү вәллааһү әкбәр. Аллааһү әкбәр вә лилләәһил-хәмде" дип тәкбир әйтү мәҗбүри була (хатын-кызлар тәкбирне эчтән әйтә). Бу – Тәшрикъ көннәре дип атала. Имам вә җәмәгать белән намаз укыганда тәкбирнең вәҗиб булуының мәгънәсе – адәм балалары Җир йөзенә яшәр өчен яратылды, адәм каны коелмасын, хайван каны гына коелсын дип сөенечтән тәкбир әйтүдәдер.




# Корбан бәйрәме турында нәрсә белергә кирәк?

Ислам календаре буенча Корбан бәйрәме – Гыйд әл-әдха – зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә башлана. Быел бу бөек бәйрәм 31 нче июльгә туры килә. Ибраһим пәйгамбәрдән килгән гадәт буенча, бу бәйрәм көнне мөселманнар корбан чалалар.

### Корбан чалу 3 көннең берсендә башкарыла:

– беренче көнне (зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, ягъни 31 нче июльдә);

– һәм алдагы ике көндә (зөлхиҗҗә аеның 11 һәм 12 нче көннәрендә, ягъни 1 һәм 2 нче августта).

### Корбан чалу түбәндәге кешеләргә мәҗбүри:

– мөселман;

– ирекле;

– мосафир булмаган;

– нисаб күләмендәге малга ия кеше.

### Мөселман кешесе корбан чалуны үзе өчен башкара, әмма балигъ булмаган (бәлагатькә ирешмәгән, ягъни җенси яктан өлгермәгән) балаларың өчен корбан чалу мәҗбүри түгел:

– бер сарык (кәҗә) – бер кеше исеменнән;

– йә дөя, йә сыер – җиде кеше исеменнән.

Корбан чалу ярлы яисә сәфәрдә булган кешегә мәҗбүри түгел (хәтта соңгысы бай булса да).

Корбан чалу вакыты бәйрәмнең беренче көнендә таң вакыты белән керә, әмма җомга һәм гает намазлары үткәрелә торган шәһәрләрдә һәм зур авылларда яшәүчеләр өчен ул бары бәйрәм намазыннан соң башкарыла; кечкенә авылларда яшәүчеләр таң ату белән (иртәнге намаз вакыты керү белән) корбан чалу эшенә керешә алалар.

### Корбан чалучы кеше түбәндәгеләрне эшли ала:

– итне үз гаиләсе белән ашый;

– башка кешеләрне ашатырга (бай яки хәерче булулары мөһим түгел) яки аларга итнең бер өлешен бирергә мөмкин;

– итне гаиләсе өчен калдыра.

Әлеге мөмкинлекләрнең һәрберсеннән файдалану өчен итне 3 өлешкә бүлү киңәш ителә, һәм мохтаҗларга бирелгәне өчтән бер өлешеннән дә ким булмаска тиеш.

### Корбан чалганда түбәндәгеләр мәҗбүри:

– Аллаһы исемен әйтү (бисмилләһи);

– һичьюгы дүрт өлешнең өчесен кисү: үңәч, трахея һәм 2 кан тамыры.

Иң яхшысы – корбан чала белгән кешенең әлеге гамәлләрне үзе башкаруы.

Корбанлык хайванының Китап әһеле кешесе тарафыннан чалынуы хупланмый (хәтта барлык шартлар үтәлсә дә, корбан гыйбадәт мәсьәләләренә керә һәм ул гади чалу булып тормый).

Әгәр ике кеше үзенең хайваннарын бутаса һәм аларның һәркайсы икенче бер хайванны чалган булса – бу рөхсәт ителә һәм бер-берсенә өстәмә кайтарып түләү тиешле түгел.

Әгәр мөселман кешесе корбан чалганда Аллаһы исемен әйтергә кирәк икәнлекне белсә, әмма онытса, итне ашарга ярый; әмма махсус рәвештә әйтмәсә, бу итне куллану тыела.

"Аллааһү әкбәр" дип өстәмә сүзләр әйтү һәм хайванны кыйблага каратып яткыру мәҗбүри түгел, әмма рөхсәт ителә.

Кяфер кеше (атеист) чалган корбан итен ашарга ярамый.

### Хупланмый:

– үтмәс пычак куллану;

– пычакны хайван алдында үткенләү;

– башка хайваннар каршында корбан чалу;

– хайванны корбан чалу урынына газаплап алып бару, өстәмә җәзалар күрсәтү;

– чалганда пычак белән умырткалыкка кадәр килеп җитү һәм шунда ук башын кисеп төшерү;

– хайванның җаны чыгып беткәнче туный башлау.

### Корбанлык сыйфатында түбәндәге хайваннар файдаланыла:

– дөяләр (бер яки ике өркәчле булулары мөһим түгел);

– сыерлар, үгезләр (яки буйволлар);

– сарыклар (яки кәҗәләр).

Атлар корбанлык хайван сыйфатында файдаланылмый.

Хайваннар рөхсәт ителгән юл белән алынырга тиеш.

### Югарыда саналганнардан тыш, һәрбер хайван үзенең билгеле бер яшенә җиткән булырга тиеш:

– дөя – биш яшьтән алып һәм аннан зуррак;

– сыер – ике яшьтән алып һәм аннан зуррак;

– сарык – бер яшьтән алып һәм аннан зуррак.

### Корбанлык хайван сыйфатында түбәндәге хайваннар файдаланылмый:

– ике күзе сукыр яки бер күзе сукыр булса;

– һичьюгы бер аягы аксак булса, әгәр аның аксаклыгы күренеп торса һәм корбан чалу урынына хайван үзе килеп җитә алмаса;

– авыру, ябык булса;

– колагы яки койрыгы киселгән булса, яисә колагы яки койрыгының күп өлеше киселгән булса (әгәр күпчелек өлеше булса, рөхсәт ителә).

### Корбанга чалу рөхсәт ителә, әгәр дә:

– тумыштан мөгезе булмаса, шулай ук мөгезе сынган булса (чөнки корбан чалу мөгез белән бәйле түгел);

– кастрацияләнгән булса;

– кычыту авыруы белән авырса (чөнки әлеге авыру хайванның тиресенә тарала).

### Әгәр хайванны сатып алганда ул сәламәт булса, аннары аны корбан итеп чалу ярамый торган кимчелекләре ачыкланса:

– корбанлыкның хуҗасы бай булса – ул аны икенчесенә алыштырырга тиеш;

– әгәр ярлы булса – ничек бар, шулай калдыра.

*Аллаһы Тәгалә корбан чалучыларның корбаннарын кабул итсә һәм Үзенең рәхмәте белән бүләкләсә иде. Гаиләләрегезгә, туганнарыгызга һәм якыннарыгызга бу дөньяда һәм Ахирәттә тынычлык һәм иминлек, бәхет телибез!*

# Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы

*Дәвамы. Башы алдагы санда*

Ә халык нәрсә соң? Ярсуыннан нишләргә белмәгән мөшрикләр болай дип әйтә:

**"Нәмруд һәм аның кешеләре: "Аны яндырыгыз һәм илаһларыбызга ярдәм итегез! Әгәр (аларга ярдәм) кылачак кешеләр булсагыз (Ибраһимга газапларның иң катысын бирегез)", – диделәр".**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:68

Ибраһим галәйһиссәламнең «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүррасүлүллаһ» дигән сүзләре кавемдәшләренең шулкадәр ачуын чыгара, алар иң кырыс җәза таләп итә башлыйлар. Җәза үзен озак көттерми – бөтен кавем белән Ибраһим галәйһиссәламне яндыруга әзерли башлыйлар. Моның өчен бергәләп – ирләр һәм хатыннар, балалар һәм картлар утынлыкка дип агач кисеп, коры ботаклар җыеп, учакка тезәләр. Учак тау хәтле биек булган, ул бер көнлек юл ераклыгыннан да күренеп торган. Аның ялкын телләре күкләргә ашып, уйнаклап, янынннан очып барган кошларны көйдергән. Шуннан соң шәйтан бу кешеләрне катапульта ясарга өйрәткән. Аның ярдәмендә Ибраһим галәйһиссәламне учакка ташларга тиеш булалар.

Ләкин Ибраһим галәйһиссәламнең Аллаһы ярдәменә ышануы бу уттан да көчлерәк була. Бу мизгелдә ул: «Хәсбияллаһу вә нигъмәл-вәкил / Миңа Аллаһы җитә. Ул иң яхшы Ярдәмче», – дип кабатлап тора. Раббыбыз аны ишетә, калдырмый һәм учакка очкан мәлдә аңа Җәбраил галәйһиссәламне җибәрә. Җәбраил галәйһиссәлам аннан болай дип сорый:

– И, Ибраһим! Сиңа ярдәм кирәкме?

Аллаһы Тәгалә Үзенең барлык колларына булыша. Әмма аларга сабыр булу мөһим. Кешеләр исә күбесенчә вакыйгаларны ашыктыра, кечкенә авырлыкларны да җиңә алмыйча, Раббыбыздан ярдәмне тиз арада килер дип көтә. Ибраһим галәйһиссәлам мөэминнәр өчен сабырлык өлгесе булып тора. Ул төрмәгә ябыла, үлем җәзасына тартыла, бөтен халыкка каршы ялгызы чыга... Ләкин хәтта куллары һәм аяклары белән бәйләнгән килеш катапультага терәлеп торганда да ярдәм әле килеп җитмәгән була. Ул аңа утка таба очкан мизгелдә генә ирешә. Һавада аңа Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламне җибәрә. Хактыр ки, пәйгамбәрләргә дә Үзенең ярдәмен Яратучыбыз сабыр иткәннән соң гына күрсәтә, һәм аларга җиңү насыйп итә.

Шулай итеп, утка таба очып барган Ибраһим галәйһиссәлам Җәбраил галәйһиссәламгә җавап бирә:

– Миңа синнән берни кирәкми.

– Ә Аллаһыдан нәрсә сорар идең?

– Миңа Аның хәлемне күреп белүе дә җитә.

Ягъни Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы аның хәлен белүендә бер шикләнмичә, насыйбына риза булып, әмеренә буйсынырга әзер була. Ул: "Әгәр дә Раббыбыз миңа янарга язмаган булса, Ул мине уттан саклап калачак. Аннан "Уттан коткар!" дип сорауның мәгънәсе нидә? Мин Аллаһы теләгәнне телим һәм Аның теләгәнә каршы килгәнне теләмим", – дип фикер йөртә. Тәвәккәл кылу менә шул була!

Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

**"(Алар аны зур бер ут эченә аткан вакытта) Без: "И ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!" – дидек".**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:69

Шушы әмердән соң ут эченнән су чыганагы бәреп чыга, кызыл гөлләр үсеп чәчәк ата. Аллаһы Нәмруд халкы яккан учакны гөлбакчага әйләндерә. Җәбраил галәйһиссәлам ярдәмендә Ибраһим галәйһиссәлам учакның нәкъ уртасына – шушы гүзәллеккә килеп урнаша.

Игътибар итегез, Аллаһы Тәгалә утка салкын булырга гына түгел, тыныч булырга да куша. Югыйсә, Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтүенчә, ут Ибраһим галәйһиссәламне өшетерлек кадәр салкын булыр иде.

Бу көнне җирнең һәр тарафында ут яндыру сәләте бетерелә, бер генә кеше дә учак яндыра алмый.

Ибраһим галәйһиссәлам исә ут эчендә җиде көн буе утыра. Соңыннан ул бу көннәрне гомеренең иң яхшылары дип атый.

### Ибраһим галәйһиссәламнең Нәмруд белән сөйләшүе

Ибраһим галәйһиссәлам утка ташлангач, Нәмруд аны югарыдан күзәтеп тора һәм аның гөлбакча эчендә тыныч кына утыруына шакката:

– И, Ибраһим! Сине яклаучы Раббың дөрестән дә бөек. Ләкин уттан чыга алырсыңмы син?

– Әлбәттә, чыгам.


– Синең янда кемдер бар. Кем ул?

– Ул – фәрештә. Раббым аны минем белән сөйләшү өчен җибәргән.

– Алайса мин шуның кадәрле кодрәткә ия синең Раббыңа атап корбан чалам.

– Раббыма иман китермичә, синең корбаннарың кабул булмаячак.

Шулай да Нәмруд үзенекен итә һәм, иман китермичә, 4 мең үгез һәм тагын бик күп сарыкны корбан чала. Кызганыч, ул үзен илаһ дип бәяләвен дәвам итә, чөнки тәкәбберлегеннән котыла алмый һәм Аллаһы насыйп иткән иксез-чиксез байлык һәм хакимлеккә ия була.



Уттан тере чыккан Ибраһим галәйһиссәламне Нәмруд янына алып киләләр. Томаналыгыннан арына алмаган халык бу хакимне күргән саен баш игән. Ибраһим галәйһиссәламнең сәҗдә кылмаганын күреп, Нәмруд котырына:

– Ни өчен син миңа баш имисең?

– Мин сәҗдәне Раббыма гына кылам.

– Кем соң синең Раббың?

Аллаһы бу хакта Коръәндә болай дип әйтә:

**"(И, Расүлем!) Аллаһы аңа падишаһлык бирде, дип (узынып) Раббысы (Аның берлеге) хакында Ибраһим (галәйһиссәлам) белән сүз көрәштергәнне (Нәмрудны) күрмәдеңме? Менә (Нәмрудка) Ибраһим (галәйһиссәлам): "Минем Раббым - (үлеләрне) терелтүче дә, җаннарны алучы да!" – дигән иде. Ул исә: "Мин дә (үлем җәзасы бирелгән кешене гафу итеп, җанын саклап) терелтәм дә (теләгән кешемне үлем җәзасына тартып) җаннарын да алам!" – диде. (Аның бу сүзеннән никадәр ахмак булганын аңлаган) Ибраһим (галәйһиссәлам): "Һичшиксез, Аллаһы (һәр иртә саен) кояшны көнчыгыштан чыгара, син (бер генә мәртәбә булса да) аны көнбатыштан чыгар!" – диде. (Шулвакыт) Кяфер аптырашта калган иде. Аллаһы (һидаятьне кабул итүдән качып, үз-үзләрен зарарга салган) залимнәр кавемен һидаять итми".**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:258

Моңа җавап итеп Нәмруд үлем җәзасына тартылган ике тоткынны чакыртып алып, берсен үтертә, икенчесен гафу итеп азат итә. Соңыннан Ибраһим галәйһиссәламгә борылып: "Күрдеңме: мин дә гомерне өзә дә, бирә дә алам", – дип әйтә.

Билгеле, Ибраһим галәйһиссәлам кешене тудыру һәм үтерү турында түгел, ә Раббыбызның дөньядагы һәрнәрсәне юктан бар һәм бардан юк итә алуы хакында сөйләде. Дөньяны барлыкка китерүче һәм Яратучы – бердәнбер Раббыбыз, Аннан башка илаһ юк. Ибраһим галәйһиссәлам Аңа гыйбадәт кылырга чакырып дәгъват кыла. Ул Нәмрудка мондый тәкъдим ясый:

– Минем Раббым кояшны көнчыгыштан чыгара, син исә аны көнбатыштан чыгарып кара.

Нәмруд мәсхәрәгә кала һәм хурлана. Ул Ибраһим галәйһиссәламне уттан тере чыгарган Аллаһы Тәгалә бөтен халык алдында моны эшли алачагын һәм шуннан соң бар мөшрикләрнең иман китерергә теләячәген аңлый. Хакимнең куркуы юкка булган – Ибраһим галәйһиссәламнең дәгъватына иярү өчен халыкка аның уттан котылуын күрү дә җитә. Шулай итеп, кешеләр иман китерәләр. Риваятьләрдә аларның иң беренчесе булып Лут ышана, дип әйтелә.

Соңыннан Яратучы, Ибраһим галәйһиссәламне барлык золымнар һәм дошманнардан саклап, аларны җәзага тартып, юк итә. Мисал өчен:

**"Алар аңа зур бер хәйлә кылырга теләделәр. Без исә аларны иң зур зарар күргән кемсәләр хәленә төшердек".**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:70

Раббыбыз Үзенең яраткан барлык колларын да шулай золымнардан коткара. Алар исә үз чиратында, Ибраһим галәйһиссәлам шикелле үк, Аллаһыга итагать кылырга, иманнарын ныгытырга һәм сабыр булырга тиеш.

*Дәвамы киләсе санда*

**■ Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Корбан чалу көннәре – мәрхәмәтлелеккә юл

Раббыбыз вакытның Хуҗасы булып тора. Без яшәгән дөнья тирәли үткән еллар, айлар, атналар, көннәр, сәгатьләр, хәтта мизгелләр булсынмы – барысы да Аллаһы Тәгаләгә буйсынып, Аның кушкан тәртипләре белән баралар. Күп очракта сәгате – сәгатькә, минуты минутка туры килгән һәм Бөек Хуҗабызның Үзе тарафыннан сайланып куелган билгеле бер вакытлар бар. Һәм әлеге вакыт өзекләре, җәдвәлебезнең калган көннәреннән аеруча бәрәкәт вә уңыш дәрәҗәсе белән аерылып тора.

Раббыбыз зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнен бөекләп, моның хакында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«[Иртән агарып килгән] Таң белән ант итәмен! [Зөлхиҗҗәнең башындагы] Ун төн белән дә [ант итәмен]!»**

«Фәҗер / Таң», 89:1-2

Адәм баласы тарафыннан бу көннәрдә кылынган изгелекләр Раббыбыз каршында иң яхшылары булып исәпләнә. Аларның дәрәҗәсе турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйтә: «Аллаһы бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекләргә караганда күп мәртәбә ныграк ярата». Моны ишетеп сәхабәләр аңардан: «Ий, Аллаһының Илчесе, әгәр дә башка көннәрдәге эш Аллаһы юлындагы дошманнар белән көрәш булса дамы?» – дип сораганнар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Әйе, хәтта бу эш Аллаһы юлында көрәш булса да. Әмма Аллаһы юлына чыгып, үз-үзен һәм үз мөлкәтен корбан иткән кешеләрдән тыш», – дип җавап кайтарган.

Ошбу мөбарәк вакытның һәрбер мизгелен изгелектә куллану мөселманга зур бурыч булып тора. Иң баштан фарыз гамәлләребезне (намазларыбызны) тәртипкә салсак, аннары булдыра алган кадәр мөстәхәб гыйбадәтләребезне арттыру тиешледер. Беренчесе күбрәк ураза тотса, икенчесе күбрәк садакасын бирсә, өченчесе күбрәк зикер-тәсбихен әйтсә, дүртенчесе күбрәк Коръән укыса, бишенчесе җәмгыятькә карата изгелекләрен арттырса бу, һичшиксез, Аллаһы каршында безнең дәрәҗәне үстерүдә зур бер өлеш кертү булачак.

Олуг хаҗ гыйбадәтен кылу да мөселманнарга шушы мөбарәк вакытта кушылган. Безнең дин кардәшләребез зөлхиҗҗә аеның сигезенче көнендә Мәккә шәһәре тирәли җыелып, тугызынчы көндә Гарәфәт тавы дип аталган изге җирлеккә юнәләләр. Ошбу урында бөтен хаҗилар кояш баеганчыга кадәр кулларын күтәреп, Аллаһыга догалары белән ялваралар. Ә менә без, хаҗга бара алмаганнар, үзебезнең туган якларыбызда махсус Гарәфә көне рузасын тотабыз. Бу гыйбадәт хакында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә: «Гарәфә көнендә тоткан ураза өчен Аллаһы үткән ел һәм киләсе ел гөнаһларын кичерәчәк», – дип әйткән. Ягъни бер көнлек руза, ике еллык хатагөнаһларыбыздан арынып өчен, гаҗәеп бик зур бер форсат булып тора.

Шулай ук икенче бер хәдистә Гарәфә көне хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһының Үз колларын җәһәннәм утыннан Гарәфә көненнән дә күбрәк коткарган башка көне юктыр. Дөреслектә, Аллаһы бу көннәрдә Үз колларына якынлашып, фәрештәләре каршында алар белән мактана…» – дип әйткән.



Гарәфә көнендә Аллаһыга кылган дога күп мәртәбә дәрәҗәлерәк һәм кабул булу ихтималы да зуррактыр. Моның хакында Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Гарәфә көн догасы – иң яхшы догадыр». Шуңа да хөрмәтле кардәшләрем, бу көндә һәм гомумән зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлегендә (декадасында) истигъфар (Аллаһыдан кичерү сорау) догалары белән ашыгыгыз, чөнки гади вакытта ул бер истигъфар булса, бу көннәрдә исә, Аллаһы теләсә, шул бер истигъфарның йөзләгән истигъфарга әверелү мөмкинлеге бар.

Быел, Аллаһы теләсә, Гарәфә көне 30 нчы июльгә туры килә. Шул сәбәптән, хөрмәтле кардәшләрем, бу көнне бушка уздырмагыз, булдыра алган кадәр күбрәк якын туганнарыгыз белән рузаларын тотып, садакаларын биреп, догалар белән Аллаһыга ялварып уздырырга тырышыгыз!

Зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә Корбан гаете, милади белән ул 31 нче июльгә туры килә. Бу көн шулай ук Раббыбыз каршында бик мөкатдәстер, чөнки шушы вакытта динебездә иң зур гамәл-гыйбадәтләрнең берсе – корбан чалына. Иртә белән үк мөселманнар мәчетләргә ашыгалар, анда гает намазларын кылып, җәмәгать белән тәкбирләр әйтәләр, бер-берләренә бүләкләр тараталар. Соңрак халык корбан чалу белән мәшгуль була. Итне гореф-гадәткә туры китереп өчкә бүләләр: бер өлешен авыр хәлле мохтаҗларга, икенче өлешен туганнарга күчтәнәч итеп, өченче өлешен үзеңә – корбан ашын уздырырга дип хәзерләп куялар.

Корбан бәйрәменнән соң «әййәмү-тәшрик» килә, ягъни бу көннәрдә әүвәлге мөселманнар чалынган итләрен кояш нурлары астында киптерә торган булганнар. Моның өчен, гадәттә, өч тәүлек җитә торган булган, шуңа да Исламда бу өч көн «тәшрик көннәре» дип атала һәм бу вакытны бөтен дөньядагы мөселманнар гадәттәгечә ял итеп, бер-берсенә кунакка йөреп, бәйрәм итеп уздыралар.

Югарыда әйтелгәнчә, динебездә бәйрәм көннәрендә тәкбир әйтү йоласы бар. Моның хакында бик күп риваятьләрдә телгә алына һәм алар барысы да Аллаһыны олуглау сүзләренең дәрәҗәсе турында сөйлиләр. Шуларның берсе Гомәр Әл-Фәрук радыяллаһу ганһе белән бәйле. Бохари хәзрәтләре китергән хәдистә: «Гомәр Мина җирлегендә үзенең чатырында еш тәкбир әйтә иде, ә мәчеттә булган кешеләр аның тавышын ишетеп, аның артыннан кабатларга ашыгалар иде. Алар артыннан базарда булган кешеләр дә кабатлый башлап, бар Мина җирлеге тәкбир әйтүдән тетрәп тора кебек иде…» – дип әйтелә. Ягъни, шушы көннәрдә тәкбир сүзләрен «Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Ләә иләәһә илләллааһу, вәллааһу әкбәр! Аллааһү әкбәр! Вә лилләәһилхәмде!» әйтү бик тә мөһим йола булып тора. Аны без Гарәфә көненең иртәнге намазыннан соң башлап җибәрсәк, ахыргы тәшрик көненең икенде намазыннан соң тәмамларга тиешбез.

Шулай ук динебезнең күркәм гамәлләреннән саналган корбан итен тарату гадәте бар. Бу изге эш ихлас нияттән башкарылса, Аллаһы каршында бик дәрәҗәледер, чөнки монда күп төрле саваплы эшләр бергә туплана: садака тарату вә аларны ашату, кардәшлек вә туганлык җепләрен ныгыту, кешеләрнең хәлләрен белешү вә алар өчен дога кылу, милләт вә динара дуслыкны арттыру һ.б. Шуңа да хөрмәтле кардәшләрем, чалынган корбан итләрен фәкать үзебез һәм якыннарыбызга гына түгел, ә бөтенләй таныш булмаган кешеләргә тарату динебездә олуг гамәлләрдән булып хисаплана. Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында болай дип әйтә:

**«Төнлә һәм көндез, яшерен һәм ачыктан-ачык малларын сарыф иткән кешеләргә – Раббылары катында әҗерләре [әзерләп куелган]. Аларга бернинди дә курку булмас, [дөньяда калдырган нәрсәләре өчен] алар хәсрәт тә чикмәс».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:274

Хөрмәтле кардәшләрем! Билгеле булганча, изге зөлхиҗҗә аенда бу мөбарәк тәүлекләр мөселманнар өчен зур мөмкинлекләрне үз эчләренә яшерәләр. Раббыбыз Аллаһы каршында зур әҗер-савапларга ирешү өчен, диннең тирән мәгънәләренә төшенеп, шушы ункөнлектә үз гамәл-гыйбадәтеңне арттыру хәерле.

■ **Хәбир хәзрәт Ханов,**
**Чирмешән районы, Мөшбикә**
**авылы имам-хатыйбы**

# Бренд атамасының мәгънәсе мөселман кулланучысы өчен мөһимме?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Nike компаниясе әзерләп чыгарган аяк киемнәрен һәм киемнәрне киеп йөрергә ярамый, чөнки “nike” сүзе мәҗүсилектә илаһ исеме дип ишеттем. Бу дөресме?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Спорт киемнәре бренды атамасы булган “Найк” сүзе, чыннан да, грекларда җиңү алиһәсе Ники исеменә барып тоташа.

Күп кенә брендлар һәм аларның логотиплары борынгы мифология һәм мәҗүсилек карашлары белән сугарылган. Мисал өчен, Мазда автомобиле зороастризм илаһы Ахур Мазда исеменнән алынган, бу турыда компаниянең сайтында да хәбәр ителә. Старбакс компаниясенең логотибы Синера дип аталган мифологик сурәткә кайтып кала. Мондый мисаллар шактый. Хәтта инглиз телендәге атна исемнәре дә мифологик һәм мәҗүси тамырларга тоташа: Thursday – Тора көне, Saturday – Сатурн көне. Хәтта күп кенә рус сүзләренең тамырлары мәҗүсилеккә бәйле: “врач”, мәсәлән, сихерче, күрәзәче дигән мәгънәләрне белдерә торган тамырдан ясалган.

Брендның товарын мөселманнар өчен рөхсәт ителгән-ителмәгән булу мәсьәләсенә килгәндә, без сүзнең заманча, бүгенге мәгънәсенә игътибар итәргә тиеш. Әйтик, рус телендәге “обожать” сүзе элек нәрсәнедер Аллаһыга тиңләүне белдерсә, хәзер аның бу мәгънәсе юкка чыккан. Бу мәгънә сүзлекләрдә дә иске мәгънә буларак теркәлгән. Әгәр кеше сүзгә Аллаһыга тиңләштерү мәгънәсен салмый икән, аны куллануда бернинди зарар юк.

Дәруль-ифтә Мәхмүдия (Дурбан, Көньяк Африка) хәнәфи галимнәре дә шундый ук аваздаш фәтва бирә: “Күп кенә гомумкулланылышта булган сүзләр, мәсәлән, ай атамалары (инглиз телендә), атна исемнәре, планета һ.б. төрле атамалар грек яисә рим мифологиясенә барып тоташа. Әмма аларны бүген мәгънәсен исәпкә алмыйча кулланалар. Шунлыктан, бу сүзләрне кулланырга ярый” (№ 39105 фәтвасы).

Шулай итеп, Nike киемнәрен киюне мөселманнар өчен тыйган кешеләрчә фикерләсәк, ширеккә төшмәс өчен, телдән иң элек мәгънәсе буенча мәҗүси булган барлык сүзләрне аерып алырга (ә бу мөмкин дә түгел), аннары аларны кулланылыштан алырга кирәк.

Кемнәрдер, брендларның исемнәре мифологиягә тоташуын сәбәп итеп, ул брендларны кулланмаска (Тойота машинасында йөрмәскә, айфоннар йөртмәскә, старбакста кофе эчүдән баш тартырга) мөмкин, әмма Аллаһы исеменнән бу тыюларны кертергә ярамый. Кайберәүләр, үзләренең шәхси тойгыларын фикһ хөкемнәре белән бутыйлар, алай булырга тиеш түгел.

Бүгенге көндә мөселманнарның күп проблемалары төгәл гыйлеме, махсус әзерлеге булмыйча торып, “фәтвалар бирергә” ашыгучылар аркасында барлыкка килә. Әмма фикһның хөкемнәрен – хәләл һәм харам темалары буенча – шәхси тоемлау, “миңа шулай тоела” дигән фаразлар белән бутарга ярамый. Андый чакта наданлык һәм вәсвәсәгә юл ачылачак.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!



# Тәрбиягә алынган балага мирас бүлү

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Уллыкка алу процедурасы төгәлләгән очракта, паспортка язылган балалар үги әниләре үлеменнән соң мираска ия була аламы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Мирас бүлгәндә, Ислам буенча бары кан туганнар гына исәпкә алына. Димәк, тәрбиягә алынган балалар, кыз булсынмы, малай булсынмы, ата-ананың үз баласына әверелми. Шунлыктан, мирас бүлгәндә, аларга өлеш тими.

Әмма, мирас бүлгәннән соң, варислар тәрбиягә алынган ир яисә кыз туганнарына үз теләкләре белән өлеш чыгара ала. Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә аять тә китерә:

**«(Шәригатьтә билгеләнгәнчә, мирастан өлеше булмаган) Туганнар белән ятимнәр һәм ярлылар (мирас) бүлешкәнгә шаһит булсалар, аларга да аннан (ни дә булса) бирегез һәм аларга (артыгын бирә алмаган өчен, бәрәкәт догалары кушып йомшак) яхшы сүз әйтегез (ул сүзләр битәрләү һәм рәнҗетүгә кайтып калмасын)».**

“Нисә / Хатыннар”, 4:8

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!

# Госел алу ничек башкарыла?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Әгәр борынымны, авызымны чайкап, бөтен тәнемне юсам, госел дөрес буламы? Әгәр алай гына юыну җитмәсә, госелнең дөрес тәртибе ничек?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Сезнең сорауда госелнең фарыз өлешләре саналган. Әгәр сез бу гамәлләрне тиешенчә игътибар белән башкарасыз икән, сезнең госелегез дөрес санала. Әмма сөннәттә булган гамәлләргә дә игътибар итәргә кирәк, чөнки алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән килгән. Өстәвенә, госелнең барлык сөннәтләрен дә җентекләп башкару тәнне нәҗесләрдән тулысынча чистартып бетерүгә сәбәп була, һәм тәннең барлык өлешләре дә юылып бетүгә ныклы ышанып була.

Фикһ гыйлеме буенча язылган китапларда госел алу түбәндәге тәртиптә башкарыла:

1. Гаурәт ачылганчы «бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип әйтү.
2. Госел кылырга ният итү.
3. Кул чукларына кадәр кулларны юу.
4. Тәндә нәҗес булса, нәҗесне юып төшерү.
5. Нәҗесе булмаса да, җенси әгъзаларны юып алу.
6. Тәһарәт алу, ягъни тәһарәт алганда юыла торган барлык әгъзаларны да өчәр тапкыр юу, ә башка мәсехне бер тапкыр кылу.
7. Су җыелып торган урында булса, аякларны юмый тору, чөнки җыелып торган су нәҗес белән кушылу ихтималы бар. Әгәр су җыелып тормый икән, аякларны юу.
8. Өч тапкыр тәнне су белән юып төшерү.
9. Су коюны баштан башлау.
10. Суны башта тәннең уң ягына, аннары сул ягына кою.
11. Тәнне кул белән ышкып алу.
12. Госелне өзлексез башкару.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!

■ **Булат Мөбарәков,**
**ТҖ МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе**

# Татарстанда тагын өч мәчет ачылды

## Татарстан Президенты һәм мөфти төзекләндерелгән Әҗем мәчетендә булдылар



15 нче июльдә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановn Казанның тарихи үзәгендәге кайбер әһәмиятле объектларны төзекләндерү һәм реставрацияләү барышы белән танышты. Алар арасында Әҗем мәчете дә булды. Мәчетне Рөстәм Нургалиевич Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән бергә карады. Очрашуда шулай ук ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Президенты ярдәмчесе Олеся Балтусова, Казан мэры Илсур Метшин, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре катнашты.

Рөстәм Миңнехановка төзекләндерелгән Әҗем мәчетен тәкъдим иттеләр, биредә эшләр биш ел дәвамында алып барылган иде.

## Алексеевск районы Биләр авылында мөфти катнашында яңа мәчет ачылды



23 нче июльдә, Алексеевск районы Биләр авылында яңа мәчет ачылды. Әлеге тантанада танылган кунаклар, шушы җирлектән чыккан күренекле шәхесләр, депутатлар, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, иганәчеләр катнашты. Истәлекле бәйрәм чарасы кунакларын Татарстан мөселманнары исеменнән республикабыз мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламләде. Ул иң әүвәл Коръәни Кәримнән аятьләр укыды һәм дога кылды. Алга таба мәчет төзүнең савапларына тукталып үтте: «Хәдисләрдә Аллаһы ризалыгы өчен мәчет төзетүче кешегә Ахирәттә бер сарай бүләк ителер, дип әйтелә. Аллаһы Тәгалә мәчетне төзүчеләрдән, төзелеш эшләрендә катнашучылардан разый булсын. Бу мәчеттән кеше өзелмәсен, буш тормасын, чөнки Кыямәт көнендә мәчет синең өчен шаһитлек кылачак. ИншәАллаһ, бу мәчетебез безгә каршы шаһитлек кылмас", – диде Камил хәзрәт.

## Арча районы Югары Корса авылында “Илдус” мәчете ачылды

25 нче июльдә Арча районы Югары Корса авылында яңа мәчет ачылды. Әлеге тантанада Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, ТР мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча киңәшчесе Равил хәзрәт Зөфәров, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе Илшат Галимуллин, Арча районы имам-мөхтәсибе Эмир хәзрәт Миңнемуллин, дин әһелләре, кайткан кунаклар, җирле халык катнашты.

Яңа мәчет сафка басканчы биредә яшәүче авыл халкы намазларны Курсавилар вакытында төзелгән мәдрәсә бинасында укыган. Әлеге яңа мәчетне төзетү өчен Илһам Хисамиев зур көч куйган. “Илдус” исеме бирелгән яңа мәчеттә бар уңайлыклары булган тәһарәтханә, уку сыйныфлары бар.


dumrt.ru сайтыннан

# ДИН – БӘХЕТКӘ ЮЛ



Барысыннан да бигрәк безне Аллаһы белә, чөнки Ул безнең Яратучыбыз. Ул безне ярата һәм без дә Аны һәм Аның мәхлукъларын бик яратабыз. Ул кайсы гамәлләребез бәхеткә илтәсен, ә кайсылары бәхетсезлеккә китерәчәген Белүче. Раббыбыз безнең бу дөньяда бәхетсез булуыбызны теләми. Ул начарлыклардан кисәтү өчен, адәм балалары бәхетле һәм тыныч тормыш кичерсен өчен пәйгамбәрләр җибәргән. Пәйгамбәрләр безнең кебек үк гади кешеләр булган. Әмма Аллаһы Үзе аларны башкалар арасыннан сайлап куйган. Ул аларны Үз саклавы астына алган, өйрәткән һәм пәйгамбәрлек вазифасына әзерләгән. Әлеге киң күңелле, тырыш, гадел, ышанычлы, батыр кешеләр кешелеккә Раббыбыз динен өйрәткән. Дин – ул бәхет өчен кирәкле булган тормыш белемнәре. Дин бәхетле тормыш рәвешен күрсәтә. Иң беренче чиратта Аллаһы белән, аннары үз-үзең һәм әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләрне күркәм итә.

**“Һәрбер өммәтнең [дөньяда хаклыкка өндәү, Ахирәттә шаһитлык кылу өчен билгеләнгән] расүле бар. Расүлләре килгәч, [берәүләре ышанып, икенчеләре инкяр иткәч], араларында гаделлек белән хөкем ирелә [иман китерүчеләр котыла, инкяр итүчеләр һәлак була], әмма аларга [динне ирештермичә, җавапка тартып] золым [һәм хаксызлык] ителмәячәк”.**

«Юныс», 10:47

# Адәм галәйһиссәламнән алып Мөхәммәд галәйһиссәламгә кадәр...

Һәр заманда да Аллаһы кешеләргә пәйгамбәрләр җибәреп торган. Аларны азга гына булса да ялгыз калдырмаган. Адәм галәйһиссәлам иң беренче кеше һәм тәүге пәйгамбәр, барлык кешелекнең атасы. Һәрбере-без дә Адәм галәйһиссәламнән барлыкка килгәнбез. Барыбыз да аның балалары. Адәм галәйһиссәламнән алып Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәтле бик күп пәйгамбәрләр килеп киткән. Расүлебез галәйһиссәлам – иң соңгы пәйгамбәр. Аннан соң башка пәйгамбәрләр булмаган.

Без Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яраткан кебек үк, башка пәйгамбәрләрне дә яратабыз, чөнки аларны да Аллаһы Тәгалә җибәргән һәм алар да хакыйкатькә чакырган. Аларның вазифасы – кешеләргә дөрес юлны күрсәтү. Аллаһы – бер, шулай булгач, пәйгамбәрләргә төрле чорларда иңдерелгән дин дә – бер үк. Шуңа күрә Аллаһы дине – Ислам, ә пәйгамбәрләр Ислам пәйгамбәрләре дип атала.

Без тарихтан кешеләр һәрвакытта да үзләренә иңдерелгән, аларга өйрәтелгән диннәргә хыянәт итеп яшәгәнен беләбез. Аллаһыдан килгән пәйгамбәрләр халыкка хакыйкый динне аңлатканнар. Әмма соңрак ул дин ырымнар, үзбелдекләре белән китерелгән аңлатмалар белән үзгәреп беткән. Болардан соң яңа пәйгамбәрләргә ихтыяҗ барлыкка килгән. Аллаһы Тәгалә бербер арты пәйгамбәрләр җибәреп торган. Бу расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең килүенә хәтле дәвам иткән.

Нигездә, Аллаһы Тәгаләдән иңдерелгән барлык диннәр дә бер дин булып санала. Әмма аларның асылын үзгәрткәннән соң, кешеләр бәхетле һәм әйбәт тормышта яши алмый. Һәм ахыр чиктә диннәрен калдырырга мәҗбүр була. Кешелек билгесезлектә яшәмәсен, адашмасын өчен Аллаһы Тәгалә һәрдаим пәйгамбәрләрне җибәреп, дөрес юлның кайда икәнлеген искә төшереп торган.

Безнең динебез Ислам – кешеләр тарафыннан үзгәртелмәгән бердәнбер хакыйкый дин. Аның кагыйдәләре, нигезе Изге Коръәни Кәрим китабында язылган. Бу кагыйдәләр бүгенге көнгә кадәр үзгәрмичә сакланган.

■ **Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде**

# Намазның гамәлләре, укыла торган сүрәләр һәм догалар

Һәр намаз рәкәгатьләрдән тора. Рәкәгать – билгеле бер сүзләр һәм гамәлләр тәртибе. Намаз ике, өч һәм дүрт рәкәгатьтән торырга мөмкин.

Һәр намазның беренче рәкәгате түбәндәге гамәлләрдән тора:

1. Тәкбир әйтеп (“Аллааһү әкбәр”) кулларны күтәрү.

2. Кыям – намаз вакытында басып тору.

3. Кыйраәт – намаз вакытында Коръән уку.

4. Рөкүгъ – намазда билгә тикле баш ию.

5. Каумә – рөкүгътан тураеп басу һәм бераз басып тору.

6. Беренче сәҗдә.

7. Ике сәҗдә арасында утырып тору.

8. Икенче сәҗдә.

Икенче рәкәгатьтә өстәмә гамәл барлыкка килә – кагъдә. Кагъдә – икенче сәҗдәдән соң утырып тору һәм махсус дога – “Әттәхият” (“тәшәһһүд”) догасын уку.

Һәр намазның соңгы рәкәгатендә тагы бер хәрәкәт – сәлам бирү өстәлә. Сәлам – башны башта уңга, аннан соң сулга борып, ике якка да «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ» сүзләрен әйтү.

1. Иртәнге намаз 4 рәкәгатьтән тора: 2 сөннәт, 2 фарыз.

2. Өйлә намазы 10 рәкәгатьтән тора: 4 сөннәт, 4 фарыз, 2 сөннәт.

3. Икенде намазы 4 рәкәгать фарыздан тора:

4. Ахшам намазы 5 рәкәгатьтән тора: 3 фарыз, 2 сөннәт.

5. Ястү намазы 6 рәкәгатьтән тора: 4 фарыз, 2 сөннәт.

## Намазның гамәлләре

Аяк табаннары арасында 4 бармак киңлегендә буш ара калырлык итеп кыйблага карап басарга, күзләрне сәҗдә урынына юнәлтергә. Ният кылабыз: «Аллаһы ризалыгы өчен бүгенге иртәнге намазның 2 рәкәгать сөннәтен укырга ниятләдем».

«Аллааһү әкбәр» сүзләрен әйтеп, тәкбир кылырга. Ирләр уч төпләрен кыйблага каратып, баш бармаклары колак йомшаклыгы турысына җиткәнче кулларын күтәрә. Хатыннар уч төпләрен кыйблага каратып, бармаклары кушылган хәлдә, бармак очлары иңбашы турысында булырлык итеп кулларын күтәрә. Ирләр уң кулларын сул кулы өстенә куеп, уң кулның чәнти һәм баш бармагы белән сул кулны беләзеге турысыннан бөҗралап тоталар. Шул рәвешле тоташкан хәлдә кулларны кендек астына төшереп куялар. Хатыннар исә уң куллары сул кул өстендә булган хәлдә кулларын күкрәкләренә куялар. Ирләрдән аермалы буларак, хатыннар сул кулларын уң кулның бармаклары белән бөҗралап тотмый. Шул рәвешле, сез кыямда саналасыз. Кыямда килеш «Сәнә» догасын, «Әгууҙү бисмилләһне», «Фәтихә» сүрәсен һәм бүтән бер сүрәне рәттән укырга.

### «Сәнә» догасы:

Сөбехәәнәкәл-лааһүммә вә бихәмдикә вә тәбәәракәс-мүкә вә тәгәәләә җәддүкә вә ләә иләәһә гайрүк («Аллаһым! Син һәртөрле кимчелектән өстенсең, бөтен мактаулар Сиңа, Синең исемең бик мөбарәк, даның олугтыр, вә Синнән башка илаһ юк, Синнән башкаларга гыйбадәт кылмыйбыз»).

Шуннан соң “әгууҙү”не һәм “бисмилләһ”не әйтәбез: Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. («Аллаһының рәхмәтеннән ерак булган шәйтаннан сакланып Аллаһыга сыенамын. Бу дөньяда һәркемгә дә шәфкатьле, ә Ахирәттә исә мөэминнәргә генә рәхимле булган Аллаһының исеме белән»).

Аннан соң «Фәтихә» («Әлхәм» дип тә атыйлар) сүрәсен укыйбыз:

Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмиддиин. Иййәәкә нәгъбүдү үә иййәкәнәстәгиин. Иһдинәссыйрааталь мүстәкыйым. Сыйрааталь-ләҙиинә әнгәмтә галәйһим. Гайрил-мәгдууби галәйһим үәләддааллиин. («Бөтен галәмнәрнең Тәрбиячесе, Раббысы Аллаһыга мактаулар булсын! Ул – Мәрхәмәтле, Рәхимле. Җәза көненең (Ахирәтнең) Хуҗасы. Бары тик Сиңа гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Безне туры юлга күндер. Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер»).

Аннан соң Коръәннән тагы бер өстәмә сүрә укыйбыз. “Ихлас” сүрәсе:

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль һү-үәллааһү әхәде. Әллааһүссамәде. Ләм йәлиде. Үә ләм йүүләде. Үә ләм йәкүлләһүү куфуән әхәде.

(“Әйт: Ул – Аллаһы Бер, Аллаһы – Мәңгелек. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады. Һәм беркем Аңа тиң түгел”).

«Аллааһү әкбәр» сүзләрен әйтеп билгә тикле иелергә, ягъни рөкүгъка китәргә, һәм шул хәлдә өч тапкыр: Сөбеханә раббийәл-гаҙыйм («Олуг Раббымны пакь дип беләм»), – дип әйтергә.

Рөкүгътан тураеп басканда шул сүзләр әйтелә: Сәмигал-лааһу лимән хәмидәһ («Аллаһы Тәгалә Үзен мактаган кешенең мактавын ишетә»).

Тураеп баскач әйтелә: Раббәнәә ләкәл-хәмд («Әй, Раббыбыз, һәрбер мактау Сиңа гына тиеш»).

Сәҗдә – җиргә тикле иелү. «Аллааһү әкбәр» дип әйтеп, башта тезләрне, аннары кулларны, аннан соң маңгай белән борынны идәнгә тидерергә; бу вакытта баш куллар арасында була, аяклар җирдән аерылмый, күзләр борынга карый. Шул хәлдә түбәндәге сүзләр 3 тапкыр кабатлап әйтелә: Сөбехәәнә раббийәл-әгъләә («Бөек булучы Раббымны пакь дип беләм»).

«Аллааһү әкбәр» сүзләрен әйтеп, маңгайны җирдән аерырга һәм тезләнеп утырырга. Куллар тезләргә куела, күз карашы үз алдыңа юнәлгән була. Берничә секунд утырганнан соң, «Аллааһү әкбәр» сүзләре белән икенче сәҗдәгә кителә һәм 3 тапкыр «Сөбехәәнә раббийәл-әгъләә» дип әйтелә. «Аллааһү әкбәр» сүзләре белән (икенче рәкәгатьне кылыр өчен) торып басырга һәм кыямда булган хәлдә кулларны берләштереп, кендек астына төшерергә (ирләр) яки күкрәк өстенә (хатыннар) куярга. Шул рәвешле беренче рәкәгать тәмамлана.

Икенче рәкәгать беренчесе кебек үк кылына, бары “Сөбеханәкә” догасы укылмый, “әгууҙү” әйтелми. Алга таба икенче сәҗдәгә кадәр беренче рәкәгатьне укыган кебек укыйбыз, ә икенче сәҗдәдән соң утырабыз. Алга таба икенче сәҗдәгә кадәр беренче рәкәгатьне укыган кебек укыйбыз, ә икенче сәҗдәдән соң утырабыз. Куллар тез өстендә, күз карашы үз алдында (тезләргә карыйбыз). Шушылай утырган килеш рәттән «Әттәхият», «Салават», «Раббәнә әәтинә» догалары укыла:

– Әт-тәхиййәәтү лилләәһи вәссаләүәәтү вәт-таййибәәт. Әс-сәләәмү галәйкә әййүһән-нәбиййү вә рахмәтул-лааһи вә бәракәәтүһ. Әс-сәләәмү гәләйнәә үә галәә гибәәдил-ләәһиссаалихиин. Әшһәдү әл-ләәә иләәһә илләллааһу вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһүү вә расүүлүһ.

(«Тел гыйбадәтләре дә, тән гыйбадәтләре дә, мал гыйбадәтләре дә – һәркайсы Аллаһы Тәгалә өчен. Әй, Пәйгамбәребез, Сиңа Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Сәлам безгә дә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Шулай ук гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд – Аллаһы Тәгаләнең колы һәм илчесе»).

– Аллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Аллааһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибраһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид.

– «Раббәнәә әәтинә фид-дүнйәә хәсәнәтән вә фил-әәхыйрати хәсәнәтән вә кыйнәә гәҙәәбәннәәр» («Әй Раббыбыз! Безгә дөньяда һәм Ахирәттә яхшылык бир, безне җәһәннәм газабыннан сакла»).

– Сәлам бирү. Элек башны уңга борып, аннан соң сулга борып (күз карашы иңбашына юнәлгән), ике тапкырында да сәлам әйтергә: Әссәләәмү галәйкүм вә рәхмәтуллааһ («Сезгә Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын»).

Моннан соң кулларны күтәреп, бу дога укыла:

Аллаһуммә әнтәс-сәләәмү вә минкәс-сәләәмү тәбәәрактә йәә ҙәл-җәләәли вәл-икраам

(«Йә Рабби, Син һәрбер бәладән саклаучы һәм тынычлык Синнән генә. Син – мөбарәк Зат, әй олуглык һәм хөрмәт Иясе Аллаһы»).

Шуның белән 2 рәкәгатьле намаз тәмам була.

4 рәкәгатьтән торган намазларны уку тәртибе:

а) 4 рәкәгатьтән торган фарыз намаз:

1 нче рәкәгать: Сөбеханәкә, Әгууҙү, Бисмилләһ, Фәтихә, өстәмә сүрә.

2 нче рәкәгать: Бисмилләһ, Фәтихә, өстәмә сүрә.

Беренче утыру: Әттәхият.

3 нче рәкәгать: Бисмилләһ, Фәтихә.

4 нче рәкәгать: Бисмилләһ, Фәтихә.

Соңгы утыру: Әттәхият, Сәлам догасы, Раббәнәә әәтинә.

б) 4 рәкәгатьле сөннәт намазлар:

1 нче рәкәгать: Сөбеханәкә, Әгууҙү, Бисмилләһ, Фәтихә, өстәмә сүрә.

2 нче рәкагать: Бисмилләһ, Фәтихә, өстәмә сүрә.

Беренче утыру: Әттәхият.

3 нче рәкәгать: Бисмилләһ, Фәтихә, өстәмә сүрә.

4 нче рәкәгать: Бисмилләһ, Фәтихә, өстәмә сүрә.

Соңгы утыру: Әттәхият, Сәлам догасы, Раббәнәә әәтинә.

Сөннәт намазы фарыз намазыннан 3 һәм 4 нче рәкәгатьләрдә Фәтихә сүрәсеннән өстәмә сүрә укылуы белән аерыла.

**dumrt.ru сайтыннан**

# Эстония мөселманнары: татар сәүдәгәрләрен кемнәр дип уйлаганнар?




Газетаның үткән санында ислам диненең төньяк Балтыйк илләренә үтеп керү тарихы турында сөйләнгән язма басылган иде. Теманы дәвам иттереп, мәкалә XIX гасырда Эстониядәге татарлар тормышын яктыртуга багышлана.

Алдан билгеләп үткәнчә, 1721 елда Рәсәй белән Швеция арасында дәвам иткән Төньяк сугышыннан соң Ништад Тынычлык килешүе төзелә. Бу килешү нигезендә Эстония Рәсәй империясе составына керә. Яңа территория Эстляндия губерниясе дип атала башлый.

Таллинда (Ревель) Төньяк сугышы тәмамланганнан соң казармаларда хәрби татарларны фатирларга урнаштыру башлана. Соңрак казармадан ерак булмаган урында кайбер отставкадагы татарлар торак йортлар төзер өчен җир биләмәләре ала башлый. Бу район Татар бистәсе исемен ала. XIX гасырда бистәнең үзәк урамы Татари – Татар урамы дип атала башлый. Бу исем бүгенге көнгә кадәр сакланып калган.

XIX гасырда ислам динен тотучы хәрбиләргә үзләренең имамнары булган гыйбадәт йортларына ия булу хокукын биргәннәр. Алдан имамнарны солдатларның үз араларыннан сайлап куйсалар, соңрак рәсми рәвештә Өфедә, Ырынбур Диния нәзарәте җыелышында билгеләп куя башлыйлар. Алар җомга һәм бәйрәм намазларын үткәрергә, мәрхүм булган мөселманнарны озатуны оештырырга һәм шулай ук башка дини ихтыяҗларны – метрика кенәгәләренә беркетеп бару мәсьәләләрен (бала туу, никахлар, үлем) канәгатьләндерергә тиеш була.

Татарларның күпчелеге Рәсәй Диңгез Флоты составына керә. Мәсәлән, Ласнамяэ Эстония хәрбидиңгезе шәһәрчегендә мөселманнарның үзләренең гыйбадәт йортлары була. Моннан тыш, мөселманнарны Таллинга һәм Палдискига авыр эшләр башкарырга җибәрә башлыйлар. Бик еш болар патша хакимиятенә каршы баш күтәргән башкорт һәм татар халкы була. Палдискидагы сөргендә башкорт батыры Салават Юлаев һәм аның әтисе Юлай Азналин гомерләренең соңгы көннәрен үткәрә.

Архивтагы чыганаклар буенча, 1834 ел белән 1862 еллар арасында Таллинда даими рәвештә 50 кеше яшәгән һәм аларның күпчелеге татар кешеләре булган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу халык санын алу вакытында хәрби хезмәттә булучылар исәпкә алынмаган, шуның өчен чынлыкта мөселманнарның саны күбрәк булган. Аларның җирле халыкның кызларын кияүгә алу очраклары да булган. Таллин шәһәре архивында 1838 елда татар-мөселман кешеләре белән эстонияле хатын-кызлары арасында ике, ә 1842 елда бер никах беркетелгәне билгеле.

Татарлар тагы да күпләп Эстониягә 1861 елда, крепостной хокук кире кагылганнан соң килә башлый. Бу вакыйгадан соң крестьян татарларының бер өлеше сәүдә белән шөгыльләнә һәм сәяхәт кылып йөрүче кайбер татарлар Эстониягә килә. Алар арбаларга утырып сәяхәт кылган рәвештә сәүдә эшләрен алып бара. Шуңа күрә дә бу татарларны ялгышып, сукбай чегәннәр дип уйлыйлар.

Соңрак дөнья гизеп йөрүче бу сәүдәгәрләр Эстониядә төпләнеп, анда үзләренең кечкенә генә кибетләрен ачып җибәрә. Бу кибетләргә килүчеләр, гадәттә, татарлар һәм калган мөселманнар була. Күпчелеген Нижгар губерниясе (хәзерге Нижгар өлкәсенең Кызыл Октябрь районы) Сергач өязенең Куй Суы (Овечий овраг) авылыннан чыккан кешеләр тәшкил итә.

Нижгар өлкәсе Кызыл Октябрь районының Куй Суы (Овечий овраг) авылына кергәндә. Нигездә, әлеге татар авылларыннан чыгучылар Таллинда сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый.

■ **Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**




Таллин (Ревель) урамындагы йорт, 1917 ел



Нижгар татарлары

# Ата-анага итагать кылу

Исраиллеләрнең улы арасында бик тәкъвалы бер кеше яшәгән. Аның улы һәм бозавы булган. Берьюлы ул бозауны урманга алып барган да: "Йә, Аллаһым, минем улым үсеп җиткәнче бу бозауны сакла", – дип әйткән. Күпмедер вакыт үткәннән соң бу кеше вафат булган. Бу вакытта бозау үсеп, урта яшькә җиткән. Ул кемне күрсә дә, кеше күзеннән качып киткән.

Малай да үсеп җитеп, сөекле улга әйләнгән. Бу игелекле бала беркайчан да әнисенә ике тапкыр әйттермәгән, берсүзсез аны тыңлый торган булган. Төнне ул өч өлешкә бүлгән: өчтән берен намазда үткәргән, икенче бер өлешен йокыга биргән, ә калган өлешен әнисе янында булуга багышлаган. Көндезләрен егет урманга барып, чыбык-чабык җыеп, базарга алып барып саткан. Кәсеп итеп алган акчасын да өч өлешкә бүлгән: бер өлешен садака итеп тараткан, икенче өлешен үзенә калдырган, калганын әнисенә биргән.

Беркөнне әнисе улын чакырып алып болай дип әйткән: "Әтиең сиңа мирас итеп бозау калдырды. Ул аны урманга алып барып, Аллаһыга әманәт итеп тапшырды. Урманга барып, Ибраһимның, Исхакның һәм Исмәгыйльнең Раббысына дога белән мөрәҗәгать итеп, бозауның сиңа килүен сора. Ул хайванда кояш нурлары чагыла. Әйтерсең лә, бу нур аның тәненнән чыга. Төсе һәм матурлыгы өчен аны "алтын белән бизәлгән бозау" дип атыйлар".

Егет урманга килеп, әлеге бозауны күреп ала да: "Мин сине Ибраһимның, Исхакның, Исмәгыйльнең һәм Ягъкубның Раббысының исеме белән чакырам. Минем яныма кил", – дип чакыра.

Бозау йөгереп, егет каршына килеп баса. Ул хайванны муеныннан тотып, өенә алып кайтып китә. Бу вакытта бозау телгә килеп:

– Ий, әнисенә яхшы мөнәсәбәттә булган, аңа итагать иткән егет! Минем өстемә утыр. Бу җәяү барганга караганда җиңелрәк, – дип әйтә.

– Миңа әнием син әйткәнне эшләргә кушмады. Ул миңа "аны муеныннан тот" дип кенә әйтте.

– Исраил улларының Раббылары белән ант итәм, әгәр син минем өстемә утырган булсаң, миңа беркайчан да авыр булмас иде. Үз юлыңны дәвам иттер. Әгәр син бу тауга үзең белән барырга кушкан булсаң, әниеңә карата булган яхшы мөнәсәбәтең өчен, ул сиңа иярер иде.

Моннан соң егет бозауны әнисенә алып кайта. Әнисе аңа болай дип әйтә:

– Улым, син фәкыйрь, бер әйберең дә юк. Көннәр буе утын җыю, төннәреңне гыйбадәттә үткәрү сиңа авырлык китерә. Бозауны базарга алып барып сатсаң сиңа яхшырак булыр.

– Миңа аны күпмегә сатарга?

– Өч динарга сат, әмма минем белән киңәшләшмичә сәүдә килешүен төземә.

Базар бәясе буенча бозау өч динарлык бәягә тиң була. Егет хайванны базарга сатуга алып бара. Аллаһы Тәгалә Үзенең бөеклеген күрсәтер һәм ана кешегә карата яхшы мөгамәләдә булучыларга нинди әҗер-саваплар биреләчәгеен хәбәр итәр өчен, кеше сурәте биреп фәрештә җибәрә. Фәрештә егеттән болай дип сорый:

– Бу бозауны ничә сумга сатасың?

– Мин аны өч динарга сатам, әмма әнием ризалыгы белән генә.

– Әниеңнән сорама, ә мин синнән бу бозауны алты динарга алам.

– Син миңа бу хайван өчен аның авырлыгы кадәр алтын бирсәң дә, мин аны әниемнең ризалыгыннан башка сатмаячакмын.

Шуннан соң егет әнисенә кайтып: «Бер кеше миңа бозау өчен алты динар тәкъдим итте. Миңа нишләргә?» – дип сорый.

Ана:

– Базарга барып, минем ризалыгымны алу шарты белән, бозауны алты динарга сат, – дип әйтә.

Егет яңадан хайванны базарга алып бара һәм тагын фәрештә килеп:

– Әниеңнең ризалыгын алдыңмы? – дип сорый.

Егет:

– Әни алты динардан ким сатма һәм минем ризалыгымны алып сәүдә килешүе төзе дип әйтте, – дип җавап бирә.

– Мин сиңа уникe динар бирәм, тик әниеңә берни әйтмә.

Егет бу тәкъдимне кабул итми һәм әнисенә кайтып барысын да сөйләп бирә. Әнисе аңа болай дип әйтә:

– Сиңа килүче кеше – ул адәм кыяфәтендәге фәрештә. Ул сине тикшерә. Кабат килгәннән соң аннан: "Син миңа нишләргә киңәш итәрсең: бу бозауны сатыйммы әллә калдырыйммы?" – дип сора.

Базарда кабат кеше кыяфәтендәге фәрештәне очраткач, егет аннан:

– Миңа нишләргә: бу бозауны сатыйммы әллә калдырыйммы? – дип сорый.

Фәрештә аңа:

– Әниеңә кайтып әйт: "Бу бозауны сатма. Көннәрдән бер көнне аны Муса галәйһиссәлам сатып алыр. Ул аңа Исраил улларының берсен үтерүчене ачыклар өчен кирәк булачак. Шул көн җиткәч, сез хайванны аның тиресе сыйдыра алган кадәр алтын күләмендә сатып җибәрерсез", – дип әйтә.

Фәрештәнең сүзләренә колак салып, алар бозауны сату фикереннән баш тарталар. Аллаһы Тәгалә Исраил улларына нәкъ менә әлеге хайванны корбан итәргә куша. Исраиллеләр Аллаһыдан бу хайван турында бөтен нечкәлекләренә кадәр ныклап төпченә. Шул рәвешле, әнисенә итагатьле булганы өчен, егет Аллаһының чиксез рәхмәте һәм юмартлыгы белән бүләкләнә.



### Нәсыйхәт:

– Балаларының тәкъва һәм динле булып үсүләрен теләгән ата-аналар, иң беренче чиратта, үзләре шәригать кануннарын үтәп яшәргә тиешле.

Күрүебезчә, егетнең әтисе, Аллаһыга тәвәкәллек кылучы тәкъвалык иясе булган. Бу аның бозауны урманга алып барып, Аллаһы саклавы астында калдыруында чагыла.

– Егетнең әнисе дә әтисе кебек үк була. Рухи яктан камил булганга күрә, ул сатып алучының фәрештә булуын ачыклый.

– Төннең бер өлешен гыйбадәттә үткәрү мөһим. Аллаһының сөекле колларының барысы да, иң беренче чиратта пәйгамбәрләр, бу гамәлгә өстенлек бирә иде. Кайберләре төнне тулысы белән, икенчеләре яртылаш, башкалары төннең бер өлешен гыйбадәткә багышлый торган була. Мәсәлән, Расүлебез галәйһиссәлам өчен тәһәҗҗед намазы вәҗиб хөкемендә булган. Моннан тыш, фарыз намазларыннан соң, тәһәҗҗед намазы иң мөһим намаз булып санала.

– Кеше милкенең бер өлешен садака итеп бирергә тиеш. Әмма бу гамәлне үтәп, үз гаиләсен мохтаҗ хәлендә калдырмавы мөһим.

– Тыелган гамәлләр кушмасалар, ата-ананы тыңлау, аларга итагать кылу фарыз хөкемендә.

Коръәндә болай дип әйтелгән:

**"Менә Локман улына вәгазьләп: «И, улым! [Бернәрсәне дә] Аллаһыга ширек кушма. Һичшиксез, ширек – бик зур золым", – дип әйтте.**

**Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. [Боларның барысы өчен дә, иң элек, Яратучың буларак] Миңа һәм [шуннан соң барлыклар арасыннан яратылыш сәбәбең булган] ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа [булачак]".**

«Локман», 31:13-14

Күрүебезчә, иң зур гаделсезлек булып саналган Аллаһыга тиңдәш кылмау әмереннән соң, ата-анага яхшы мөгамәләдә булу әмере килә. Шулай ук Аллаһы Тәгалә Үзенә рәхмәтле булудан соң, ата-анага рәхмәтле булу әһәмиятен ассызыклый.

Ата-анага яхшы мөгамәләдә булу хакында күп аятьләрдә һәм хәдисләрдә язылган. Кеше, әлеге сорауга кагылышлы хезмәтләрне өйрә-нергә, ата-анага карата булган вазифаларын белергә һәм аларны үтәргә тиеш.

– Кеше кирәксез сораулар бирүдән тыелырга тиеш. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Исраил улларына бозау чалырга куша. Әгәр алар теләсә кайсы бозауны чалган булсалар, Аллаһының әмерен үтәгән булырлар иде. Әмма бу кешеләр сорау бирүләрен дәвам иттерә. Хәтта ки, аның төсе турында да ачыклык кертүен сорыйлар. Бу сораулар аларга бернинди дә файда китерми, ә, киресенчә, мәсьәләне катлауландыра гына. Ахыр чиктә алар хайван өчен аның тиресе тулы алтын бирергә мәҗбүр була.

■ **"Рухуль-Бәйан" китабыннан тәрҗемә**

# Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе




## Исеме

Габдрахман бине Гауф – ислам диненнен беренчеләрдән булып кабул итүчеләрдән. Җәһилият заманында аның үз исеме Габделкәгъб (Кәгъбәтулла колы), башка риваятьләр буенча Габделәмер булган. Шулай ук ул Әбү Мөхәммәд куньясе белән дә танылган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә шәһәрендә Әркамә йортында сәхабәләре белән җыелышып очраша торган булган. Шул йортта Габделкәгъб ислам динен кабул иткән һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа Габдрахман дип исем биргән.

## Тууы

Габдрахман бине Гауф фил елы вакыйгаларыннан егерме ел үткәч, якынча 580 елда Мәккә шәһәрендә дөньяга килгән.

## Гаиләсе

Габдрахман бине Гауфның әнисе – Сыйфә бинте Гауф бинте Гадил-Харис бинте Зөһрә бинте Киләб. Әнисе ислам динен кабул итеп, Хәбәшигә һиҗрәт кылган. Әтисе – Харис исемле, корәеш кабиләсенең Бәну Зөһрә нәселеннән.

## Һиҗрәт кылуы

Беренче мөселманнар кебек үк, Габдрахман бине Гауфка да авыр сынаулар аша үтәргә туры килгән. Алар кебек ул да диненә тугры булып, бу сынауларга нык торган. Башка мөселманнар кебек ул да, үз динен саклап калу максатыннан, Хәбәшигә (Эфиопия) һиҗрәт кылган.

Аллаһы Тәгалә тарафыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның сәхабәләренә Мәдинәгә күчү рөхсәт ителгәч, Габдрахман бине Гауф Аллаһы ризалыгы өчен һиҗрәт кылучыларның алгы сафында булган. Мөселманнарга Мәдинәгә һиҗрәт кылырга әмер бирелгәч, Габдрахман бине Гауф башка мөселман-нар белән беррәттән Мәдинә шәһәренә күчкән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөһаҗирләр белән әнсарларны туганлаштыра башлагач, ул Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһене Сәгъд бине Әр-Рабигъ Әл-Әнсари белән туганлаштыра. Сәгъд бине Әр-Рабигъ Әл-Әнсари Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә: "Йә абыем минем! Мин Мәдинәдәге иң эре милекче. Минем ике бакчам бар. Моннан тыш минем ике хатыным бар. Шушы ике бакчамның кайсы ошый, шунысын үзеңә ал. Хатыннарымның да кайсына күзең төшә, шуны үзеңә сайлый аласың. Мин аны аерып, син аңа өйләнерсең", – дип әйткән. Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе: "Сиңа, синең якыннарыңа һәм малыңа Аллаһының рәхмәте булсын. Син миңа базарның кайда икәнлеген күрсәт әле", – дип әйткән. Сәгъд бине Әр-Рабигъ Әл-Әнсари аңа базарның кайдалыгын күрсәткән һәм Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе базарда сату итә башлаган. Товарларны сатып алган, саткан, үзенә керем туплаган. Габдрахман бине Гауф сәүдә эшләрендә бик оста булган, шуңа да тиз арада кәсеп кылып, мал туплап мәһәр белән өйләнгән. Ислемайлар сибенеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килгән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам гаҗәпләнеп аннан: "Сиңа нәрсә булды?" – дип сораган. Ул: "Мин өйләндем", – дип җавап кайтарган. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам аннан кәләшкә күпме мәһәр бирүе турында кызыксынган. Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе: "Мин аңа бер нават алтын бирдем", – дип җавап кайтарган. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: "Бер сарык белән булса да туй яса. Аллаһы Тәгалә сиңа рәхмәтен ирештерсен", – дип әйткән. Габдрахман бине Гауф: "Бу сүзләрдән соң минем тормышым алга китте. Теләсә нинди ташны күтәреп алсам да, мин шул таш астында йә алтын, йә көмеш табармын кебек тоела иде", – дип искә алган.

## Юмартлыгы

Габдрахман бине Гауф Бәдер һәм Өхед сугышларында үзен аямыйча көрәшкән. Өхед сугышында башка гаскәриләр куркып калганда да, ул түземлек күрсәткән, нык торган. Бик нык яраланса да, авыртуларга түзгән.

Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе бик ярдәмчел булган. Юмартлыгы бер яктан фәкыйрьләргә тисә, икенче яктан, хәрби әзерләнүләргә ярдәм иткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм гаскәрне хәрби поход өчен кирәк-яраклар белән тәэмин итү максатыннан, үзенең сәхабәләренә болай дип мөрәҗәгать иткән: "Мин хәрби экспедиция җибәрергә уйлыйм, мөмкинлеге булганнарыгыз үзенең ярдәмен күрсәтә ала". Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бу сүзләрен ишеткәч, өенә йөгергән һәм тиз арада килеп тә җиткән: "Йә Аллаһының Илчесе! Минем дүрт мең акчам бар. Мин аның икесен Аллаһы юлында сарыф итәм, ә икесен балаларыма калдырдым", – дип әйткән. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам аның бу гамәленнән риза булып: "Малыңны биргән өчен дә һәм үзеңә калдырганың өчен дә Аллаһы Тәгалә сиңа Үзенең рәхмәтен ирештерсә иде", – дип әйткән.

Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһенең юмартлыгына тагын бер мисал карап китик.

Бервакыт Шам җиреннән Мәдинәгә 700 дөягә төялгән мал белән Габдрахман бине Гауфның чираттагы кәрваны кайта. Дөяләрнең саны шулчаклы күп булган ки, кәрван Мәдинә җиренә килеп туктагач, җир тетрәп куйган. Шәһәр эчендә бик каты тавыш күтәрелгән. Гайшә радыяллаһу ганһә бу тавышны ишетеп: "Бу тетрәү нәрсәне аңлата, нинди тавыш бу?" – дип сораган. Аңа 700 дөягә төялгән Габдрахман бине Гауфның кәрваны турында хәбәр иткәннәр. Шулвакыт Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип әйткән: "Мин ишеттем, Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: "Мин Габдрахман бине Гауфның ничек җәннәткә шуышып кергәнен күрдем", – дип әйтте".

Бу шатлыклы хәбәрне ишеткән Габдрахман бине Гауф канатланып, Гайшә радыяллаһу ганһә янына йөгергән һәм аннан: "Йә, мөэминнәрнең анасы, син бу хәбәрне Пәйгамбәр галәйһиссәламнең үзеннән ишеттеңме?" – дип сораган. Гайшә радыяллаһу ганһә: "Әйе", – дип җавап кайтарган. Габдрахман бине Гауф моны белгәч, тагын да шатланып: "Әгәр булдыра алсам, мин җәннәткә үз аякларым белән атлап керәм", – дип әйткән һәм бөтен кәрванны фида кылган.

## Пәйгамбәр галәйһиссәлам каршында өстенлекләре

Мөселманнар армиясе Табукъка походка чыккан. Әлеге походта Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе бер мөселман да ирешә алмаган дәрәҗәгә ирешкән.

Бервакыт намаз вакыты җиткәч, Пәйгамбәребез галәйһиссәламне таба алмаганнар. Шуңа да Габдрахман бине Гауф барлык мөселманнарны җыеп, үзе имам булып басып, җәмәгать намазын җитәкләгән. Беренче рәкәгать тәмамлангач, гыйбадәт кылучылар арасына Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам дә кушылган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә оеп, намаз укырга аның артыннан баскан. Соңрак, җәмәгать намазытәмамлангач,Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: "Пәйгамбәр галәйһиссәламгә намазда үз өммәтенең изге кешесенә иярү тыелмаган".

## Вафаты

Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе идарә иткән вакытта, Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһе инде олы яшьтә булган. Шул сәбәпле, тыныч һәм тыйнак тормыш рәвеше алып барган. Ул 652 елда, Мәдинә шәһәрендә вафат булган. Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһенең табутын Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең абзасы Сәгъд бине Әби Вәккас алып барган. Җеназа намазын хәлифә Госман бине Гаффан укыган. Соңгы юлга озатучы Гали бине Әби Талиб: "Син төрле ялганнардан читләшеп, бу дөньяның асылына төшендең һәм аңладың. Аллаһы Тәгалә сиңа Үзенең рәхмәтен ирештерсен", – дип әйткән.

Габдрахман бине Гауф үләр алдыннан Гайшә радыяллаһу ганһә аны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр янына күмәргә тәкъдим иткән. Ләкин Габдрахман бине Гауф андый дәрәҗәдән оялып, үзен Госман бине Мәзгун янында күмәргә кушкан. Ул Әл-Бәкыйгъ зиратына күмелгән.

■ *Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде*

# ОЛУГ ҮКЕНЕЧ

**(Әкият, әмма бик зур гыйбрәт)**



Элгәре заманда, зур булмаган салада яшәгән ди бер күркәм әтәч. Кып-кызыл кикриге, өч-дүрт төсле каурые, гаҗәеп матур купшы койрыгы аңа янындагы тавыклары арасында шактый зур абруй казанырга ярдәм итте: үз урманында чупай да купай дигәндәй, әтәч, ихатасында үзен олы, дәрәҗәле затка санап, көн дә кукраеп, шапырынып йөри иде. Ә инде һәр көнне иртән көр, көчле тавыш белән кычкыруы әтәчебезне бөтен әйләнә-тирәгә танытты: аның шома куначадан күкрәгән горур калкытып мәхәлләгә сөрән салуыннан шактый күп кеше уянды, гыйбадәт кылучылар исә күкрәк төпкеленнән чыккан шушы гайрәтле оранны иртәнге намазның азаны буларак кабул итте.

Тавыклар кавемендә бердәнбер ир заты булуыннан кайчак иләсләнеп китеп, әтәч көндезләрен дә кыт-кыт килеп ишегалдын вакыт-вакыт вәкарь аваз илә яңгырата, аннан кинәт томырылып, бер каурыйлы бикә белән аралашып алгач, канатларын җилфердәтеп биек читәнгә очып менә дә тирә-якка бик куәтле аваз салып, бу җирлектә үзенең гаять зур кадер-хөрмәткә ия шәхес булуын тагын бер кат раслап куя. Кылтаючан кошның менә шундый бар дөньяга үз барлыгымны хәбәр итәм дип укталып торган мәлендә, бер көтмәгәндә-уйламаганда, аның алдында йорт хуҗасы пәйда була. Ике учын чалбар кесәсенә тыгып, хуҗа әүвәл капыл сызгырып ала, соңыннан исә читән өстенә яңа гына кунаклаган әтәч янына басып, зәһәрлелек илә әйтә:

– Ызначыт тәк! Иртәгәдән башлап тавыштының чыкмасын! Иртән азан әйтсәң, гомумән, кычкырганыңны ишетсәм – йонаңны йолкыйм!

Шуннан соң кырыс ниятенең хаклыгын күрсәтергә теләптер, кытыршы зур учы белән әтәчебезнең артына тондырып, хуҗа аны читәннән бәреп төшерә. Шушындый сөмсез мөгамәләдән, тавыклары алдында шулай рисвай ителүдән гарьләнсә дә, әтәч “исән-имин калу барыннан да хәерле” дигән җәһәт уйның йогынтысында каударланып абзар артына кача. Хуҗаның катгый таләбеннән һәм куркыныч вәгъдәсеннән хәйран калып, ул тирән хафага төшә. “Менә сиңа мә-ә! Ни гомер мәхәлләне яңгыратып, күпләрне сокландырып әйткән азанны әйтүдән тыйсыннар әле, йә... Әкәмә-әт!” – дип уйланды ул үзалдына аулакта посып. Әмма нишләмәк кирәк, “әддарурат түбиһүл мәхзурат”, ягъни мәсәлән, “зарурият тыелганны да рөхсәт итә” дигәнгә сылтап, әтәч шушы көннән башлап тирә-юньне яңгыратып кычкырудан туктый, үзенә ирешергә мөмкин җәзадан өркеп, азан әйтүдән дә баш тарта...

Көн артыннан көн узды. Шулай рәсмән кисәтелгәннән соң, әтәч, тавышын чыгармыйча, хуҗа йортына таба сагаюлы караштыргалап, үзенең барлыгын кеше күз-колагына белдермәскә тырышып йөрде. Бер атналап вакыт үткәч, кикриге шиңгән, койрыгы салынган, пошаманга төшүдән өне качкан әтәч тавыклар арасында сүлпән генә булашып йөргән бер арада, бар дөньяны хафаландырып, аның янына янә йорт хуҗасы килеп басты. Битенә ыштыр капланган затсыз бәндәнең кыяфәтеннән сискәнеп, мескен “кикрик” куркуыннан тәмам коелып төште. “Тавыш-тыным... чыкмады бугай... Әллә... ялгыш онытылып... берәр аваз чыгардыммы, Ходаем...” – дигән кот чыккыч уйдан калтыранган әтәч гомере белән хушлашырга әзерләнде. Әмма хуҗа, янында торган буш чиләкне тибеп очырды да, учларын чалбар кесәләреннән чыгармыйча, авызын усал бөрештереп болай диде:

– Тәк... Болай дәшмичә йөрүең дә бераз ялыктырды... Әмер-фәрманымны бераз үзгәртмичә булмас! Димәк, шулай: әгәр бүгеннән башлап тавыклар кебек кыткыламасаң, бөтен йоннарыңны йолкып атам!

Чын ир затына хас горурлыгын, “әтәчлеген” гаять кимсетә торган шушы яңа таләптән ачуы кабарса да, хуҗаның “матри аны!” дип бармагы белән явызларча янап алуыннан соң, әтәч вәгъдә ителгән җәзаның аяныч нәтиҗәсен күз алдына китереп, шунда ук тавыкларча кытаклап куйды. Шуннан китте инде: көн тудымы, ишегалдына чыгып, элекке тавыклар “нәчәлниге”, йортның ачык тәрәзәсенә шомлы карашын ташлый-ташлый, янындагы “ханымнарга” кушылып кытаклап йөрде. Баштарак бик гарьләнсә дә, тора-бара ничектер ияләште дә кебек: кикриге белән койрыгын яшеребрәк йөрергә тырышып, тавыкларча кыткылдавын дәвам итте.

Кая гына атлавына карамастан купшы койрыгы артыннан калмаса да, янаган җитди хәвеф хакында хәбәрдар булу әтәчкәйне хатын-кыз җенесендәге кавемдәшләреннән әллә ни аерылмаска мәҗбүр итте. Дөнья, шулай итеп, тынычланды кебек, әмма... бу ишегалдында бәла аяк өстендә йөри шул: бер ай тирәсе узгач, бераз онытылгангадыр, тавыкларча кытаклый-кытаклый азык чүпләп гамьсез йөргән әтәч янында кояш яктысын каплап, хәвефле шәүлә пәйда булды. Ул йорт хуҗасы иде...

– Тәк... – диде шәүлә, алдан кабул ителгән карарны катгый фәрман рәвешендә игълан итәргә ниятләп. – Әгәр... иртәгәдән башлап... башка тавыклар шикелле йомырка сала башламасаң... башыңны чабып сине чалачакмын!

Шуннан соң шәүлә юкка чыкты, кинәт мәнҗерәп киткән әтәч исә күзен йомып җиргә сеңде. Хуҗаның пәрие кагылган чагында ишегалдына чыкканын шәйләмичә яшеренергә өлгерми калган өчен бик тә, бик тә битәрләде үзен мескен кошкай. Ләкин инде соң иде: үзенә белдерелгән таләпне берничек тә үти алмаячагын уйлап куюдан, ул, өмете өзелеп, ирексездән елап җибәрде. Бу вакытта якты дөнья белән хушлашу котылгысызлыгыннан битәр, аның җаны башка сәбәп илә өтелде. Шуны уйлаудан бичара мәхлукны олуг үкенеч хисе биләп алды, һәм өстенә төшкән зур хәсрәттән өзгәләнеп, ул үз-үзенә әйтте:

– Ий, Аллам! Әгәр азан әйтүемне туктатмаган булсам, ӘТӘЧ булып үләр идем...

***

**КЫСКАЧА НӘСЫЙХӘТ:**

Кызганыч, ләкин безнең арабызда да шушы әкияттәге әтәч шикелле горуррак холыклы, гыйбадәтне гадәткә әйләндереп, аны үзен башкаларга белдерү нияте белән кылучы кешеләр бар. Ниндидер сынау-авырлык килгәндә, шундый мин-минлек сыйфатына ия булучыларга Аллаһы Тәгаләнең ярдәм итмәве гаҗәп хәл түгел. Ул ярдәмне тоймагач, алар еш кына шәйтанның куркытуына каршы көрәшергә талпынып та карамыйча, ул кушканны шундук үтәргә әзер тора. Әмма барыбызга мәгълүм: әгәр Аллаһка ихлас сыенсаң, дога белән мөрәҗәгать итсәң, бу куркытуның нигезендә бернинди хәтәр-хәвеф юк икәнен тоеп, аңлап була. Ә иң мөһиме – нәрсә генә булуга карамастан, иманыңа, динеңә тугры булып калу. Бу тормыш – сынау, һәм һәрвакытта да безнең өчен әзерләнгән һәрбер сынауда “ӘТӘЧ”, ягъни МӨСЕЛМАН булып калу – бик җаваплы, әһәмиятле бурычыбыз (гомеребез тәмамлануга яки дәвам итүгә карамастан). Ахырчиктә һәр кешенең олуг максаты, җир йөзендәге вөҗүднең асыл-мәгънәсе – Аллаһ разый булырлык итеп яшәп, мәңгелек ахирәт тормышына чын МӨСЕЛМАН булып, ягъни ихлас иманлы хәлдә күчү...

**Ришат хәзрәт Курамшин, Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

■ ДҮШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 "Таз Малай" мультфильм
09:45 Шөкер Хуҗа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Бер хәдис – бер җавап
11:40 Җан авазы
11:50 Иң гүзәл исемнәр
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 Шекер Ходжа
13:15 Малец-Удалец
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 "Таз Малай" мультфильм
18:45 Шөкер Хуҗа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Бер хәдис – бер җавап
20:40 Җан авазы
20:50 Иң гүзәл исемнәр
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

■ СИШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 "Таз Малай" мультфильм
08:45 Шөкер Хуҗа
09:00 Иң гүзәл исемнәр
09:10 Балам-багалмам
09:30 Мәслихәт
09:50 Хикмәтле хикәяләр
10:00 Намазга өйрәник
10:20 Бер хәдис – бер җавап
10:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:45 Мукабаля
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 Шекер Ходжа
12:40 Малец-Удалец
13:00 Ученые Ислама
13:20 Есть вопрос – есть хадис
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 Таз Малай мультфильм
17:45 Шөкер Хуҗа
18:00 Иң гүзәл исемнәр
18:10 Балам-багалмам
18:30 Мәслихәт
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:00 Намазга өйрәник
19:20 Бер хәдис – бер җавап
19:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ученые Ислама
22:20 Есть вопрос – есть хадис
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

■ ЧӘРШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 Мәслихәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Шөкер Хуҗа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Бер хәдис – бер җавап
11:40 Җан авазы
11:50 Иң гүзәл исемнәр
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 Шекер Ходжа
13:15 Малец-Удалец
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 Таз Малай мультфильм
18:45 Шөкер Хуҗа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Бер хәдис – бер җавап
20:40 Җан авазы
20:50 Иң гүзәл исемнәр
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

■ ПӘНҖЕШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 Таз Малай мультфильм
08:45 Шөкер Хуҗа
09:00 Иң гүзәл исемнәр
09:10 Балам-багалмам
09:30 Мәслихәт
09:50 Хикмәтле хикәяләр
10:00 Намазга өйрәник
10:20 Бер хәдис – бер җавап
10:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:45 Мукабаля
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 Шекер Ходжа
12:40 Малец-Удалец
13:00 Ислам без стереотипов
13:20 Халяль-лайфстайл
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 "Таз Малай" мультфильм
17:45 Шөкер Хуҗа
18:00 Иң гүзәл исемнәр
18:10 Балам-багалмам
18:30 «Мәслихәт»
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:00 Намазга өйрәник
19:20 Бер хәдис – бер җавап
19:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ислам без стереотипов
22:20 Халяль-лайфстайл
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

■ ҖОМГА
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 Мәслихәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Шөкер Хуҗа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Иң гүзәл исемнәр
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 Шекер Ходжа
13:15 Малец-Удалец
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 Мәслихәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Шөкер Хуҗа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Иң гүзәл исемнәр
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Минбар
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

■ ШИМБӘ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 Балам-багалмам
08:50 Иң гүзәл исемнәр
09:00 «Таз Малай» мультфильм
09:15 Шөкер Хуҗа
09:30 Хәзинә
09:45 Һөнәрләр
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Әлифба сабаклары
10:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:00 Мәслихәт
11:20 Хәдис дәресләре
11:40 Мукабаля
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 Шекер Ходжа
12:40 Малец-Удалец
13:00 Ислам без стереотипов
13:20 Халяль-лайфстайл
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 Балам-багалмам
17:50 Иң гүзәл исемнәр
18:00 «Таз Малай» мультфильм
18:15 Шөкер Хуҗа
18:30 Хәзинә
18:45 Һөнәрләр
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Әлифба сабаклары
19:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:00 Мәслихәт
20:20 Хәдис дәресләре
20:40 Мукабаля
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ислам без стереотипов
22:20 Халяль-лайфстайл
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

■ ЯКШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Сүз эчендә хикмәт бар
08:30 Мәслихәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Шөкер Хуҗа
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Иң гүзәл исемнәр
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 Шекер Ходжа
13:15 Малец-Удалец
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Сүз эчендә хикмәт бар
17:30 Мәслихәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Шөкер Хуҗа
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Иң гүзәл исемнәр
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Минбар
21:00 Шекер Ходжа
21:15 Малец-Удалец
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гор-

## Ильяс хәзрәт Җиһаншинның “Остазлар эзеннән барсак, югалмабыз. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсе тарихы” китабы дөнья күрде.




ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Ильяс хәзрәт Җиһаншинның “Остазлар эзеннән барсак, югалмабыз. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсе тарихы” китабын бастырды. Авторның үз сүзләре белән әйткәндә, әлеге басма Ислам диненең иң мөкатдәс кыйммәтләрен безгә гасырлар аша түкми-чәчми китереп җиткергән имамнарыбыз, остазларыбыз, мөдәррисләребез, хәзрәтләребез, абыстайларыбыз, мөгаллимнәребез, әби-бабайларыбыз һәм әти-әниләребез истәлегенә багышлана.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан интернет аша заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.

**Тел.:** +7 (960) 072-74-63

**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09

**Интернет-кибет:** huzurshop.ru
(https://huzurshop.ru/)/




## « Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2020 елның икенче яртыеллыгына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 156 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru
сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон:
+7 (843) 598 09 42

## КАЗАН ӨЧЕН АВГУСТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Сәхәр тәмам/ иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.08.2020 | 01:48 | 03:48 | 12:00 | 17:13 | 19:49 | 21:19 |
| 02.08.2020 | 01:50 | 03:50 | 12:00 | 17:11 | 19:47 | 21:17 |
| 03.08.2020 | 01:52 | 03:52 | 12:00 | 17:10 | 19:45 | 21:15 |
| 04.08.2020 | 01:54 | 03:54 | 12:00 | 17:09 | 19:43 | 21:13 |
| 05.08.2020 | 01:56 | 03:56 | 12:00 | 17:08 | 19:41 | 21:11 |
| 06.08.2020 | 01:58 | 03:58 | 12:00 | 17:06 | 19:39 | 21:09 |
| 07.08.2020 | 02:00 | 04:00 | 12:00 | 17:05 | 19:37 | 22:07 |
| 08.08.2020 | 00:08 | 04:02 | 12:00 | 17:04 | 19:34 | 22:03 |
| 09.08.2020 | 00:25 | 04:03 | 12:00 | 17:02 | 19:32 | 21:58 |
| 10.08.2020 | 00:36 | 04:05 | 12:00 | 17:01 | 19:30 | 21:54 |
| 11.08.2020 | 00:45 | 04:07 | 12:00 | 16:59 | 19:28 | 21:50 |
| 12.08.2020 | 00:53 | 04:09 | 12:00 | 16:58 | 19:25 | 21:45 |
| 13.08.2020 | 01:00 | 04:11 | 12:00 | 16:56 | 19:23 | 21:41 |
| 14.08.2020 | 01:06 | 04:13 | 12:00 | 16:55 | 19:21 | 21:37 |
| 15.08.2020 | 01:12 | 04:15 | 12:00 | 16:53 | 19:18 | 21:33 |
| 16.08.2020 | 01:18 | 04:17 | 12:00 | 16:51 | 19:16 | 21:29 |
| 17.08.2020 | 01:23 | 04:19 | 12:00 | 16:50 | 19:14 | 21:25 |
| 18.08.2020 | 01:28 | 04:21 | 12:00 | 16:48 | 19:11 | 21:21 |
| 19.08.2020 | 01:33 | 04:23 | 12:00 | 16:46 | 19:09 | 21:17 |
| 20.08.2020 | 01:37 | 04:25 | 12:00 | 16:45 | 19:07 | 21:14 |
| 21.08.2020 | 01:42 | 04:27 | 12:00 | 16:43 | 19:04 | 21:10 |
| 22.08.2020 | 01:46 | 04:29 | 12:00 | 16:41 | 19:02 | 21:06 |
| 23.08.2020 | 01:50 | 04:31 | 12:00 | 16:39 | 18:59 | 21:02 |
| 24.08.2020 | 01:54 | 04:33 | 12:00 | 16:38 | 18:57 | 20:59 |
| 25.08.2020 | 01:58 | 04:34 | 12:00 | 16:36 | 18:54 | 20:55 |
| 26.08.2020 | 02:02 | 04:36 | 12:00 | 16:34 | 18:52 | 20:52 |
| 27.08.2020 | 02:05 | 04:38 | 12:00 | 16:32 | 18:49 | 20:48 |
| 28.08.2020 | 02:09 | 04:40 | 12:00 | 16:30 | 18:47 | 20:45 |
| 29.08.2020 | 02:13 | 04:42 | 12:00 | 16:28 | 18:44 | 20:41 |
| 30.08.2020 | 02:16 | 04:44 | 12:00 | 16:26 | 18:42 | 20:38 |
| 31.08.2020 | 02:19 | 04:46 | 12:00 | 16:24 | 18:39 | 20:34 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Июль саны, №7 (300)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2751
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче июльдә таратыла.
График буенча бу санга 27 нче июль көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.